Зөфәр
ГЫЙМАДИЕВ

# *Исеңдәме?..*

# *Помнишь ли ты?..*



Зөфәр ГЫЙМАДИЕВ

# *Исеңдәме?..*

# *Помнишь ли ты?..*

Казан
2018

УДК 821. 512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Г92

Төзүчесе, чыгарылыш өчен җаваплы
(составитель, ответственный за выпуск):
*Факил САФИН*, филология фәннәре кандидаты

*Вера ХӘМИДУЛЛИНА* тәрҗемәсе
Перевод *Веры ХАМИДУЛЛИНОЙ*

**Гыймадиев Зөфәр**

Г92 Исеңдәме?..: шигырьләр, җырлар = Помнишь ли ты?..: стихи, песни / Зөфәр Гыймадиев (Вера Хәмидуллина тәрҗемәсе) Казан; 2018. – 144 б.

Бу җыентыкка туган ягын, туганнарын, якыннарын чын күңелдән яраткан Зөфәр Гыймадиевның шигъри мирасы туплап бирелә.

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (Рос=Тат)-5

© Гыймадиев З.Х., 2018
© Хәмидуллина В.П., тәрҗ., 2018

## *Эшләп чыныккан иңсә түзә ул*

Мин, Гыймадиев Миннезөфәр Хәммәт улы, 1942 елның 18 июнендә Менделеев районы Бәзәкә авылында туганмын. Тууым турында сүз кузгаткач, шунысын да әйтим, һәр кешенең дөньяга килүендә бер сер бар сыман. Минем «серем» шунда: әтием 1941 елны, сугыш башлану белән үк, яу кырына китә. Сугыш башындагы хикмәтләрне бүгенге буын кино-телевидение, аерым истәлекләрдән чыгып белә торгандыр, әмма чын мәхшәрне үз күзләре белән күргән кешеләр ул хакта артык сөйләшергә яратмыйлар иде. Чөнки аны аңлап та, аңлатып та бетерергә мөмкин түгел. Менә шушы мәхшәрдә әтием авыр яраланып, Казанга госпитальгә кайта. Әнием, хәлен белергә дип, күчтәнәчләр алып, мең мәшәкать белән әти янына барып кайта... Билгеле вакыт үткәч, мин туганмын. Ходайның рәхмәте белән миңа шулай гомер бирелгән. Гомерем гел эш,

хезмәт белән үтте дисәм, артык булмас. Бүгенге көнгә кадәр җир гаме, дөнья гаме җанны җилкендерә, бер генә нәрсәгә дә битараф була алмыйм. Тумыштан шулай язган, күрәсең.

Инде чын-чынлап үзем турында ни әйтим? Алай искитәрлек бернәрсә дә юк, тудык, үстек, эшләдек – шул гына. Авылдагы, илдәге яшьтәшләремнең биографиясе минекеннән әллә-ни аерылмыйдыр. Шулай да «үзем турында үзем» дигәндәй, тормыш юлым турында кайбер сәхифәләрне теркәп калдырасы иттем.

Безнең бәхеткә, әти сугышта берничә мәртәбә яраланса да, исән калды. Ул сугыш тәмамланып, берничә ай үткәч, 1945 елның октябрь аенда гына өйгә кайтып керде. Миңа ул чакта дүрт яшьләр тирәсе булгандыр. Әти кайтканда, көз булуга карамастан, капка төбендә чуер ташлар белән уйнап утырганым истә. Кемдер әнигә әтинең сугыштан кайтып килүен хәбәр итеп өлгергән. Өйдә ду купты. Олы абый мине күтәреп алды да, әтине каршы алырга томырылды. Йөгерәсе ара шактый ерак иде әле. Менә шунысы хәтердә.

Ул чакларда безнең авылдан Бондюгка туры юл бар иде. Юл Моймырда дип аталаган әрәмә аша уза иде. Шуннан Тихие Горага юл китә. Күп-

медер чапкач, күрәбез, юлдан әкрен генә үгез җиккән арба сөйрәлә. Арбада кара перчатка кигән бер абзый утырган. Янында дилбегә тоткан икенче агай да бар. Абый ачыргаланып: «әти!» дип кычкырып җибәрде. Үгез туктады. Кара перчаткалы абый безнең икебезне берьюлы күтәрергә итә, аны кулы бик нык имгәнгән – яраланган иде. Гомер буе шул яралы кулының сызлавына түзеп яшәде. Бу очрашу өндә булганмы, төштә күргәнменме, аны өздереп кенә әйтә дә алмыйм.

Әти кайткач, тормыш үз җаена кайта башлады.

Балачагым, үсмер елларым Бәзәкә дә үтте. Бәләкәйдән эш тә эш инде. Бәләкәй арба белән чокыр-чакырдан печән ташу дисеңме, эт яки бозау җигеп Тау астындагы чишмәдән су ташу дисеңме – әкияти мизгелләр булып хәтердә яшиләр. Үсә төшкәч, әти-әнинең кул арасына кереп, саллырак эшләргә тотындым. Һәрнәрсәгә үземнең тырышлыгым, авылча үҗәтлек белән ирештем дисәм, хата булмас. Мәктәпкә барырга китаплар кирәк. Өлкәннәрдән берсе дә акча бирәм дими, чөнки ул чакта акчасы да булмагандыр. Нинди авыр, хикмәтле еллар иде бит ул сугыштан соңгы дәвер. Һәр адымга – җитмәүчелек, кая барып бәрелмә – юклык сиздерә. Китап

сатып алырга да акча табу үземнең эшем булып калды – тәки җаен таптым: бакчада җиргә коелган алмаларны җыям да, Тихие Горы пристанена алып барып сатам. Алма саткан акча күп булмаса да, кибеткә кереп, тәмле ипи алып кайтам, китап алырга да акчам җитте...

Бәзәкә урта мәктәбен 1959 елда тәмамладым. Дөресен әйтим, укуым җиңел генә бармады. Көтелмәгән каршылыклар чыгып куя иде. Эш шунда, мине әти нигәдер гел үз янында йөртәсе килә иде. Кая бара – мине үзеннән калдырмый. Әтинең иң яраткан улы булдым дисәм, башка туганнарым үпкәләмәсен. Без җиде бала бик тату үстек, хәзер дә аралашып яшибез, әмма әтинең миңа карашы үзгә булды. Моны аерып әйтү кирәк сыман тоелды. Әти сугыштан кайтуга, баштан-аяк колхоз эшенә чумды. Иң элек ферма мөдире булды, ул дәвердә хуҗалыктагы иң авыр тармак иде ул. Ул чакта фермалар зур, маллар да ишле – сыер, сарык, атлар, кош-корт күп асрала. Колхоз үзе дә районда иң эре хуҗалыклардан санала иде. Әти савып алынган сөтне үгез җигеп, май заводына башта үзе илтеп йөрергә тиеш булды, соңрак бу җаваплы вазыйфаны икенче кешегә йөкләп, ат белән илтә башладылар. Мин һәрчак әти янында йөрим, хәлдән килгәнчә авыр

бидоннарны күтәрешәм, малларны карарга булышам. Соңрак әти, яралары ныграк сиздерә, җәфалый башлагач, кибеткә сатучылык эшенә керде. Үзебезнең авыл белән генә чикләнми, товар сатарга базарга – Бондюгка кадәр барып җитә иде. Мине дә үзе белән ала инде. Әти юлга чыгар алдыннан, иртә таңнан мине уята. Иң теңкәгә тигәне шул – йокы туймый. Сабый чакның тәмле йокысы миңа азрак эләкте... Әти яхшы сатучы булды, чут салырга оста иде, товар бәясен чутлый башласа, чутның олы төймәләре күз иярмәс тизлек белән шалт та шолт биешеп кенә торалар. Исем китеп карап тора идем. Ул заманда башка исәпләү җайланмалары юк иде, бөтен эш шул чут ярдәмендә хисапланды. Хәзер уйлап куям, дүрт сыйныф белемле булса да, әтинең ул дәвердә үк эшмәкәрлеккә һәвәслеге булган бит! Бәясен яки фасонын килештереп бетермичә, авыл халкы читкәрәк тибәргән товарны Удмуртиягә, Алабугага, Гөлширмәгә алып барабыз. Төн буена күзгә йокы керми, иртүк базар башлана. Шулай итеп, әтинең яраткан улы булуым үземә шактый авырга төште. Гаиләбез ишле, башка балалар мәктәпкә китәләр, әти мине укырга да җибәрми, мәктәп турында сүз кузгалса: «Миңа булышырга бер егет кирәк бит, – дип, сүзгә нок-

та куя. – Укып кем баеган, ат җигәрсең, колхозда эшләрсең, тамагың тук, өстең бөтен булыр», – дип, үзенчә киңәшен бирә.

Үсмер булып җитешкән мәлләр, атна-ун көн мәктәпкә бармыйча йөрдем, ахырда, әни ягыннан туган тиешле Рәшит абый Бәшәров килеп, әтине нык кына үгетләп, хәтта катгый таләп тә иткәч, әти чигенде, бик теләп мәктәпкә йөри башладым. Укуны яраттым, башсыз түгел идем. Урта мәктәпне тәмамлауга, мин уку ягын кайгыртам, әти колхозда эшлә дип аптырата. Хәтта Алабугага барып, техникумга документларны тапшыргач, имтиханнарга әзерләнәсе урынга, Минзәлә болынына печән чабарга җибәрде. Эшкә дә һәвәс идем, гармунда уйнарга да өйрәндем, егетләрне, кызларны биетеп, җырлатып, кичләрне үзебезчә ямьле итеп үткәрә идек. Халкыбыз җырларын, татар композиторларның мәгънәле җырларын бик яраттым. Хәзер дә күңелгә яттышлы җыр ишетсәм, өйрәнмичә тынычланмыйм. Ни хикмәттер гомер буе шигырь яраттым, кайчакларда, илһам килеп, үзем дә язгалап куям.

Җырга-моңга тартылуым эзсез үтмәде, мәктәпне тәмамлагач, документларны соң булса да (печән чабып йөрдем дидем ич!) Алабуга мәдәният-агарту училищесына илтеп бирдем. Им-

тиханны ничек биргәнмендер, хәтерләмим дә, минем өчен артык авыр булмады кебек, кыскасы шул – алдылар мине укырга. Беренче көнне укырга килсәм, ни күрәм – бүлмә тутырып кызлар утыра. Булса, бер-ике егет кисәге булгандыр инде. Шулай берничә көн нишләргә белмичәрәк дәресләргә йөрдем дә, ниһаять, ныклы карарга килеп, укуны ташлап, Алабугада яшәүче туганнарыбызга киттем.

Йорт хуҗасы миңа абый тиешле иде, килеп керсәм, өйләрендә миңа таныш булмаган, җитди карашлы, русчалап әйтсәк, солидный гына кеше утыра. Абый белән кунак кайда укуымны сорыйлар, авылдагы хәлләрне белешәләр. Теге җитди кеше АТП да колонна башлыгы икән. Туган абый да, кунак агай да: шоферлыкка укы, – дип, димлиләр, мәдәният-агарту училищесына ташлауны ике куллап хуплый болар, янәсе, егет эшемени ул гомер буе биеп-җырлап йөрү! Мамадышта шоферлар әзерләүче курс эшли икән, абзыйларның киңәшләрен тотып, шофер һөнәренә кызыгып дисәң, дөрес булыр, Мамадышка юл тоттым. Укырга теләгемне сизеп, шундук исемлеккә кертеп тә куйдылар. Шоферлык таныклыгы алганда миңа унҗиде яшь ярым иде.

Башта Алабуга АТПсына барып, слесарь бу-

лып эшкә урнаштым, аннан үзебезнең Бондюгка кайтып киттем. 18 яшем тулганчы шофер булып эшләргә рөхсәт итмәделәр, йөк төяүче – грузчик хезмәтендә булдым. Баржадан 60-70 килограммлы капчыкларны ярга чыгарып өябез. Тар трап селкенеп-тирбәлеп тора. Берсендә, капчык күтәргән килеш, суга егылып төштем... Унсигез яшем тулгач, йөк машинасына утырдым. Иң элек Можгадан йөк ташыдым, 1961 елны, өлкән яшьтәге шоферлар белән рәттән Башкортостандагы ерак Федоровка районына уракка җибәрделәр. Бездә юллар мактанырлык түгел иде, анда исә юл-фәлән бөтенләй юк икән. Салам түбәле өйләр, керосин лампалары. Электр турында ишетеп кенә беләләр. Шул рәвешле, цивилизациядән бик ерак якта яшәп алдык. Беркөнне өч машина белән Казахстанга җибәрделәр – Актүбә өлкәсеннән бәрәңгене бодайга алыштырып кайтырга тиеш булдык. Бер капчык уртача кыяфәтле бәрәңгегә алтын төсендәге бер капчык бодай бирәләр, өч машина бодай төяп кайтыр юлга чыктык. Мин ике тонналы вездеход машинасын йөртәм, заманасы өчен шәп машина инде бу. Кайта торгач, машинама ут капты бит. Баштан уй сызылып үтте – машинаны да, бодайны да ничек тә саклап калырга! Бу бурычны мин генә хәл итә ала идем!

Кара төтен чыгарып яна башлаган машина астына шуышып кердем дә, ягулык кранын яптым, бензин килүче торбаны өзеп, утны сүндердем.

Урак төгәлләнде, үз машинамда исән-имин туган якка кайтып киттем. Һәркайсыбызга бүләк итеп икешәр центнер бодай биреп җибәрделәр. Без кайтканда ноябрь азагы иде, ап-ак булып кар яуган, бу аклыктан күзләр камаша. Исән-имин кайтуга барлык туганнар сөенә, алардан да бигрәк үзем куанам.

Мин башкорт, казах далаларында йөргән арада яшьтәшләрем армияга китеп беткәннәр. Мине җитәкчеләребез: бер елга калдырабыз, ягъни, отсрочка бирәбез, дип, юаталар. Үземнең елгылардан каласым килми, хәрби комиссариатка киттем. Алар: «Хәл итәрбез!» – дип калдылар. Бер көнне Можгага чыгып киткәч, хәрби комиссариаттан чакырып, хәбәр җибәргәннәр. Кайтып керүгә, бу хакта миңа әйтүләре булды, шул сәгать эчендә җитәкчеләргә әйттем дә, йөкне дә бушатып тормыйча, комиссариатка чыгып йөгердем. Можгага автобус белән килдек, аннан Казанга поездда җилдердек. Татвоенкоматта биш тәүлек яткач, Көнбатышка, Львовка хезмәткә озаттылар. Разведчик Кузнецов йөргән җирләрдә хезмәт итәргә туры килде. Бандерачыларның кем

икәнен дә шунда белдем. Шәһәргә аерым-аерым чыгып йөрешле түгел иде, биш-алты солдат бергәләп чыксак кына, рөхсәт итәләр иде «увольнительный» дигән солдат ялын. Язуым матур булгач, штабта писарь булдым, шофер булып, офицерларны йөртеп алдым. Урта белемле булгач, ракеталар буенча укырга җибәрмәкчеләр иде. Бер офицер ачык итеп: «Татарларга квота юк», – диде. Хәер, үкенмим, анда алты ел укырга кирәк иде бит. Үзе бер гомер.

Хезмәт иткән урын – урман эчендә, җир астында тирән шахта. Шунда өч ел гомер узды, ике мәртәбә ялга – отпускга җибәрделәр. Миндә хәрби мәсьәлә ягына ниндидер сәер ашкыну бар иде: 1961 елда Кариб диңгезендәге киеренкелек чорында, Куба халкын яклау теләге белән Азатлык утравына ирекле рәвештә китмәкче булып рапорт яздым. Җибәрмәделәр. Аннан армиядан соң Украинада калырга исәпләдем. 1964 елда Львов хәрби-политик институтына имтиханнар биреп йөргәндә, тиз арада өйгә кайтырга чакырып язган хат алдым. Туган якларга кайтып, җиде көн үтүгә эшкә урнаштым. ЗИС –151 машинасын бирделәр. Ун тәгәрмәчле ППУ-2 (паропередвижная установка) дигән җайланмада слесарь булып эшләдем. Укырга теләк кимемәде,

Васильевода шул заманда институт дәрәҗәсендә йөргән Россия автотехника техникумы дигән уку йорты бар иде, зур теләк белән шунда барып кердем.

Өч ел укыдым, яхшы укыдым, хәтта практика вакытында Лениногорск шәһәрендә яшьләрне шоферлыкка укытып алдым. Аннан юллама буенча Алабугадагы Прикамнефть идарәсе нефтьчеләр сафына килеп кушылдым. Әни авырып киткәч, фатир бирергә дигән карарны читкә куеп, 1969 елда янә Менделеевка кайттым. Андагы АТПда техник контроль бүлеге җитәкчесе булып эшли башладым. Бер ел эчендә, хезмәтемне күреп, АТПның баш инженеры дәрәҗәсенә күтәрделәр. Сигез ел эшләдем, безнең АТПны Алабуга АТПсына кушкач, эштән киттем. Һаман да транспорт белән бәйле эш көткән мине: тагын сигез ел ОРСның транспорт бүлеген җитәкләдем.

1985 елда Менделеев районы төзелде. КПСС райкомының беренче секретаре булып Түбән Камадан Мансур Хаснуллин билгеләнде. Иң беренче итеп районда АТП төзүне максат итеп куйды ул. Ярдәмчеләренә мине эзләп табарга кушкан, очраштык, сөйләштек, аңлаштык. Миңа Алабуга АТПсының Менделеевтагы филиалын җитәкләүне йөкләделәр һәм районның мөстәкыйль

АТПсын оештыру бурычы да куелды. Дөньялар үзгәрә башлаган чак, оештыру эшләре озаккарак сузылды, шулай да 1990 елның апрель аенда СССР Транспорт министрлыгы карары белән Менделеев АТПсы төзелде. Бертавыштан мине директор итеп сайлап куйдылар. 2009 елга кадәр шул эшне башкардым.

Ул чагында Менделеевта төзелешләр чоры булды. Кая карама – төзелеш, кая карама җир актаралар, кая карама – биек краннар басып тора. Иң кирәге – транспорт чаралары. 1994 елда, ул чактагы тәртип буенча, АТПны приватизацияләдек. Сайлаучы акционерлар генераль директор итеп мине расладылар. Озак еллар дәвамында безнең предприятие районда гына түгел, республикада алдынгы саналды. Вакытында хезмәт хакы биреп бардык, салым түләүдә дә хилафлыкка юл куймадык. Иң мөһиме һәм мине куандырганы – эшлекле, инициативалы, яхшы коллектив туплый алдык. Мин моны бүгенге көннән торып, горурланып әйтәм.

Әмма... әмма... дөньялар болганды да болганды, тынычлану турында хыялланасы гына калды. Заман җилләре чәчләргә чал төшерде, безне инде төрле чара-очрашуларда «ил агалары» да дип җибәрәләр, дәвер башка, кешеләр

бүтән. АТП язмышына да кырау китереп сукты, бу масштабтагы АТПлар аерым районнарда яши алмыйлар инде, аларның көннәре санаулы кала сыман. АТП таралса, тәҗрибәле белгечләр дә кайсы кая китеп бетәчәк. Шул борчый мине. Кешенең кадере китә базар чорында... Һәммәсе шәхси кулларга күчә. Ярый инде, ни булса да, яхшыга юрыйк. Кешене өмет яшәтә бит.

Үткәннәргә карыйм... Эш тә эш дияргә дә булыр иде. Әле ир кешенең гаиләсе булырга тиеш бит. Йорт салмаган, егет үстермәгән, агач утыртмаган ир кеше буламы? Бу яктан, шөкер, гаиләм әйбәт булды. 1970 елның октябрь аенда Татар Тәкәше авылы кызы Фәридә Әхтәм кызы белән гаилә кордык. Пар канатлы булып, бәхетле яшәдек. Ике бала үстердек. 1971 елда туган Айдар улым Таулы Карабахта армия хезмәтен үтте, хәрби медаль белән бүләкләнде. Хәзер янгын сүндерү хезмәтендә эшли. Хатыны Алсу белән Нияз һәм Алия исемле оныкларымны үстерәләр. Аларга сокланып туймыйм. Кызым Алсу медицина, педагогика буенча белем туплагач, Казан финанс-экономика институтын тәмамлады, Казанда эшли. Алар минем горурлыгым!

Тормышта бернәрсә дә очраклы булмыйдыр. Минем тууым да шулай. Гыймазетдинов-

Гыймадиевлар нәселе ныклы, хезмәт сөючән, эшмәкәрлеккә һәвәс. Туганнарымның кайсын алма – нәселебезгә тап төшермәделәр, сайлаган хезмәтләрендә зур уңышларга ирештеләр. Моңа ничек сөенмисең инде! Әти-әнинең, әби-бабайларның эш сөючәнлеге, тырышлыгы, кирәк кадәр үҗәтлеге, чама хисе, яктыга омтылышы бүгенге уңышларыбызда чагыла. Безнең бүгенге нәселдәшләребез ата-аналарның эшен дәвам итеп кенә калмыйлар, аны югары баскычка күтәрүләре белән дә хуплауга лаеклылар. Үткәннәр белән бүгенгебез меңләгән җепләр белән җаннарыбызга, тормышыбызга тоташкан. Бүгенгеләр, ышанып әйтәм, әти-әниләрнең лаеклы варислары буларак, тагын да җегәрлерәк, тагын да өлгеррәк, тагын да эшлеклерәк! Шунысы сөендерә мине – туган җирнең, Татарстаныбызның язмышы да шундый гаярь егетләребез тырышлыгыннан, булдыклыгыннан тора. Рәсәйнең киләчәген мин шундый егетләр кулында дип беләм. Ни дисәк тә һәр дүрт татарның өчесе Рәсәй буенча сибелеп яши, эшли, тормыш итә бит.

Үземә килсәк, хезмәтем лаеклы бәяләнде. Җитәкчеләр эшемнән канәгать булдылар, хезмәттәшләрем ихтирам иттеләр, мин исә аларны яраттым. Эш дәверендә «Татарстанның атказан-

ган транспорт хезмәткәре», «Россия Федерациясенең мактаулы автотранспортчысы», «Россиянең шәрәфле транспортчысы», «Татарстан Республикасының Пассажир транспорты отличнигы» исеме бирелде. Менделеев районында иң беренчеләрдән булып «Алтын йөрәкле кеше» исеменә лаек булдым, аерым горурлык белән әйтәм: «Менделеев районының Мактаулы гражданины» дигән исем дә беренче булып миңа бирелде. Архивымда күп санлы Мактау кәгазьләре саклана.

Гомерләр заяга үтмәде, мин тормыштан, дөнья миннән канәгать кала шикелле. Мин шуңа ышанам. Бәхетле булыгыз, кадерле туганнарым, якташларым, милләттәшләрем!

**Зөфәр ГЫЙМАДИЕВ,**
*Менделеев шәһәре.*

# *Терпят плечи, в труде закалённые*

Я, Гимадиев Миннезуфар Хамматович, родился 18 июня 1942 года в деревне Бизяки Менделеевского района. Упомянув о своём рождении, вспомнилась истина о том, что появление в этом мире каждого человека окутано тайной. Есть тайна и моего рождения. С первых дней войны, а именно с 1941 года, мой отец ушёл на фронт. Сегодняшнее поколение знает о том, что творилось в начале войны лишь по теле– и киноверсиям, о настоящем смятении и хаосе люди, пережившие это и видевшие всё своими глазами говорить не любят. Возможно потому, что и сами до сих пор не могут понять и объяснить. В этой сумятице, тяжело раненый отец был отправлен в госпиталь Казани. Собрав гостинцы, преодолев тысячу трудностей, мама поехала его навестить, а через определённое время я появился на свет. Вот так, по милости Аллаха, мне была дарована жизнь.

Не лишним будет сказать, что жизнь моя прошла в труде и заботах. До сегодняшнего дня забота о земле, о мире вдохновляют, не позволяют оставаться равнодушным к чему бы то ни было. Видимо так жить предписано на роду.

Итак, что можно сказать о себе? Ничего удивительного: родился, рос, работал – только и всего. Биография моих сверстников-земляков не многим отличается от моей. Но, как говорится «о себе – самому» захотелось рассказать и обозначить вехи жизненного пути.

На наше счастье отец, хоть и был несколько раз ранен, остался жив. Он вернулся домой в октябре 1945 года, спустя несколько месяцев после окончания войны. Мне в ту пору было года четыре. Помню, в тот осенний день я сидел возле ворот дома и играл камешками. Кто-то успел сообщить маме, и в доме началась суета. Старший брат, подхватив меня на руки, бросился встречать отца. Расстояние было приличное... Это вот осталось в памяти.

В то время от нашей деревни до Бондюги дорога была прямая. Шла она через густой кустарник, называемый «Моймырда», а дальше уходила на Тихие Горы. Сколько мы пробежали, не помню, помню, что увидели телегу, запря-

жённую быком... На телеге сидит один дядька, в чёрной перчатке. Второй дядька шагает рядом с телегой, держа в руках вожжи. Брат отчаянно закричал: «Папа!» Бык стал. Дядька в чёрной перчатке, обхватив нас, пытается взять на руки, но изувеченная ранением рука не даёт. Отец всю жизнь будет жить, терпя боль в раненой руке. Было ли всё так или мне приснилась та встреча – не могу сказать точно.

С возвращением отца, жизнь начала входить в свою колею.

Детство и годы юности прошли в Бизяках. С малых лет – работа да работа. Запрягая собаку или телёнка, на маленькой тележке возили сено из канав-оврагов. Из ручья, что под горой – воду таскали. Эти невероятные моменты оживают в воспоминаниях. Когда подрос и начал выполнять тяжёлые работы, стал настоящим помощником отцу-матери в домашних делах. Не будет ошибкой, если скажу, что всё достигал своим старанием и деревенской настойчивостью. В школу идти, нужны были книги. Никто из взрослых не говорил, что денег даст, потому что и денег-то в то время вероятно не было. Послевоенное время тяжёлым было. На каждом шагу – жизненные лишения, куда ни кинь – нехватка даёт о себе

знать. Найти деньги на книги стало моей задачей. Выход всё-таки был найден: собираю в саду яблоки-падальцы, иду на пристань Тихие Горы и продаю. Денег от продажи хоть и немного, но хватает купить в магазине ароматный хлеб и на книги остаётся...

Бизякинскую среднюю школу окончил в 1959 году. По-правде сказать, учёба давалась нелегко. Препятствия возникали самые неожиданные. Дело в том, что отец всегда возил меня с собой, куда бы ни отправлялся. Не в обиду другим родственникам будет сказано, но был я любимым сыном у отца. Мы, семеро детей, росли очень дружно, но ко мне отец относился иначе. Об этом, мне кажется, надо рассказать более подробно. После возвращения с войны, отец с головой окунулся в дела колхоза. Сначала был заведующим фермой – это был самый трудный участок. Фермы в то время были большие: коровы, овцы, кони, птица – их разводили в огромных количествах. Да и сам колхоз считался в районе одним из крупнейших хозяйств. Отец сам отвозил на маслозавод надоенное молоко, запрягая в повозку быков. После эту работу поручили другому и выделили лошадей. А тогда я ходил с отцом, помогая ему поднимать

на телегу тяжёлые бидоны, ухаживать за скотиной. Когда раны начали особенно беспокоить, он перешёл на работу продавцом в магазин. Товар продавал не только в своей деревне, но и отвозил на базар в Бондюгу. Меня для этого дела брал с собой. Помню, перед тем, как отправиться в дорогу, на рассвете будил. Недосыпание – самое невыносимое. Редко приходилось мне досматривать сладкие детские сны... Продавцом отец был хорошим. Считал на счётах так ловко, что костяшки летали по ним с невообразимой скоростью, отбивая ритмы яростного танца. Я смотрел и диву давался. Не было тогда других счётных устройств, только на счётах всё и подсчитывалось. До сих пор удивляюсь, как отец с четырьмя классами образования в то время занимался, как сказали бы сегодня, предпринимательством! Если односельчан не устраивали фасон или цена, везли товар в Удмуртию, Елабугу, Гульширму. Ночь не смыкаем глаз, чтобы успеть спозаранку к началу базара. Вот так: обузой мне стала роль отцовского любимчика. Семья большая, все дети учатся, но только я заговорю о школе, отец возмущается: «Мне в помощники один джигит нужен, – и будто точку в разговоре ставит, – Кто из образованных,

разбогател? Будешь работать в колхозе – сыт, обут будешь!» Так говорил, будто совет на всю жизнь давал. Помню, подростком неделю другую не ходил в школу, пришёл родственник по материнской линии – Баширов Рашит абый, уговаривал отца, даже требовал, пока тот не уступил. Я с удовольствием начал снова ходить в школу. Учиться любил, башковитым был. После окончания средней школы, я хотел дальше учиться, но отец настоял, чтобы я остался в колхозе. Даже после того, как отвёз документы в техникум г. Елабуга, вместо подготовки к экзаменам, отправился сено косить. И к работе пристрастился, и на гармошке играть выучился, и вечера проводили с девчатами по-своему весело: с песнями-плясками. Тогда и полюбились народные песни и песни татарских композиторов. До сих пор, если услышу близкую душе – не успокоюсь, пока не выучу. Не удивительно, что всю жизнь любил не только мелодии, но и стихи. Иногда, когда приходит вдохновение, пишу и сам.

Увлечение музыкой и песнями не прошло бесследно, после окончания школы, пусть с опозданием, но поступил в Елабужское культпросвет училище. Как сдавал вступительные эк-

замены, не помню, но, кажется, без особого труда – короче, поступил. В первый же день, придя на занятия, увидел, что попал в женское царство: в группе одни девушки, парней один-два. Озадаченный, несколько дней походил, а потом принял твёрдое решение бросить учёбу. За советом отправился к родственникам, проживающим в Елабуге.

У хозяина дома, который приходился мне братом, вижу, сидит незнакомый мужчина. Оказался этот солидный мужчина начальником колонны АТП. И родной брат, и гость двумя руками были «за» то, чтобы я бросил своё культпросвет училище, а потом начали уговаривать пойти на шофёрские курсы, мол, не дело джигиту всю жизнь петь да плясать. Загоревшись идеей стать шофёром, я поехал поступать в Мамадыш на курсы подготовки водителей. Меня тут же включили в списки, проникнув моим страстным желанием. Когда я получил права, мне было семнадцать с половиной лет.

По окончании, работал сначала слесарем в Елабужском АТП, а затем вернулся в свою Бондюгу. За баранку до восемнадцати лет садиться не разрешалось, был определён грузчиком. Ежедневно приходилось из барж вытаскивать

на берег и складировать 60-70 килограммовые мешки. Узкий трап качался. Было дело: упал однажды вместе с мешком в воду. Когда исполнилось восемнадцать – сел на грузовую машину. Вначале возил грузы в Можгу, а в 1961 году, наравне с опытными и более старшими, был отправлен на уборку урожая в далёкое село Фёдоровка, что в Башкирии. У нас дорогами не похвастаешь, а там их вообще нет, оказывается. Крыши домов соломенные, лампы керосиновые, про электричество понаслышке знают. Вот так мы и жили, вдали от цивилизации. В один из дней меня еще с двумя машинами отправили в Казахстан, в Актюбинскую область, чтобы поменять картошку на хлеб. Меняли один к одному: за мешок картошки – мешок золотой пшеницы давали. Загрузились, обратно поехали. Я тогда двухтонный грузовик-вездеход водил. Отличная машина, но в пути почему-то загорелась. Одна только мысль в голове промелькнула: «Надо спасти и зерно и машину!» Кроме меня никто этого не сделает! Подлез под дымящую машину, закрыл кран подачи топлива, отсоединил шланг, потушил огонь.

Уборка закончилась. На своей машине, живым здоровым вернулся я в свой родимый край.

Каждому из нас тогда в подарок дали по два центнера пшеницы. Приехали домой в конце ноября, белым-бело кругом – снег лежит, белизна глаза слепит. Все родные радуются нашему возвращению, а я больше всех.

Мои сверстники, пока я ездил по башкирско-казахским степям, ушли в армию. Наши руководители успокаивали тем, что выхлопотали мне отсрочку, а я, не желая отставать от всех, сам пошёл в военкомат, где мне пообещали: «Ладно, решим!». В один из дней, пока я находился в отъезде в Можге, из военкомата пришла повестка. Узнав об этом, по возвращении, я тут же сообщил начальству и бегом помчался в военкомат, оттуда автобусом в Можгу, а дальше поездом до Казани. В Татвоенкомате мы – новобранцы провели пять суток, и нас отправили служить на Западную Украину во Львов. Службу проходил там же, где когда-то разведчик Кузнецов. Там узнал я кто такие бандеровцы. В одиночку по городу ходить запрещали, когда отпускали в увольнение, нас ходило по пять-шесть солдат. За красивый почерк меня назначили писарем при штабе, а будучи шофёром, было дело возил офицеров. Узнав, что у меня среднее образование, хотели отправить учиться на ракетчика, но один офи-

цер открытым текстом сказал: «Татарам квоты нет!». Всё к лучшему – там надо было учиться целых шесть лет. Это целая жизнь!

Местом моей службы был глухой лес, глубокая шахта под землей. Там прошли три года службы, из которых дважды довелось отдохнуть – отправляли в отпуск. Странная тяга к военному делу у меня тогда была. Во время Карибского кризиса в 1961 году, помню, писал рапорт, просился добровольцем защищать народ Кубы и Остров Свободы. Не пустили. После армии, желая остаться на Украине в 1964 году подал документы в знаменитый Львовский военно-политехнический институт, но во время сдачи экзаменов получил письмо из дома. Меня ждали там. По возвращении на родину, через неделю устроился на работу. Дали машину ЗИС-151. Работал слесарем на паропередвижной установке – десятиколёсном ППУ-2. Стремление к учёбе не пропало. Поступил в престижный в то время Васильевский автотехнический техникум, где проучился три года, а во время практики в Лениногорске сам учил молодёжь шофёрской науке. Затем, по путёвке, пополнил ряды нефтяников в Елабужском управлении «Прикамнефть». Но, заболела мама и, оставив

решение получить квартиру на стороне, в 1969 году я вновь вернулся в Менделеевск. Там, в АТП стал руководить подразделением технического контроля. Через год, увидев результаты работы, меня повысили до главного инженера предприятия. В этой должности проработал восемь лет, до тех пор, пока наше АТП не соединили с Елабужским. И дальше меня ждала работа, связанная с транспортом: следующие восемь лет я возглавлял транспортное подразделение ОРСа.

В 1985 году был образован Менделеевский район. Первым секретарём райкома КПСС назначили Мансура Хуснуллина, который решил в первую очередь создать районное АТП. Поручил помощникам разыскать меня, встретились, поговорили. Мне поручили возглавить Менделеевский филиал Елабужского АТП и поставили задачу реорганизовать его в самостоятельный районный. Организационные работы затянулись. Наступило время перемен. Всё-таки в апреле 1990 года, по решению Транспортного министерства СССР было создано Менделеевское АТП. Директором единогласно избрали меня, и до 2009 года я выполнял эту работу.

Менделеевск строился: куда ни глянь – стройка, куда ни посмотришь – роют, куда ни взглянешь – стоят высотные краны.

Без транспорта – никуда. В 1994 году, по тогдашним правилам предприятие приватизировали. Акционеры избрали меня генеральным директором. На протяжении многих лет наше предприятие считалось передовым не только в районе, но и в республике. Вовремя платили зарплату, вовремя перечисляли налоги. Самое главное, что меня радовало, мы смогли создать деловой, инициативный, хороший во всех отношениях коллектив. Об этом сегодня я говорю с гордостью.

Однако... Однако наступили тёмные времена, мир изменился, и об успокоении можно забыть. Ветер эпохи посеребрил волосы так, что на встречах-мероприятиях нас называют старейшинами, аксакалами, но времена другие и люди меняются. Работа АТП заморожена. Предприятие такого масштаба не может в наши дни существовать в рамках одного района, дни его сочтены. Кто знает, что станет с опытными специалистами после его развала. Вот что меня беспокоит. Во времена рыночных отношений обесценивается цена человека труда... Ладно, бу-

дем надеяться на лучшее. Человек и жив, пока есть светлые надежды.

Вглядываюсь в прошлое... О работе и только о работе можно говорить долго. У каждого мужчины кроме неё ещё должна быть и семья. Если не построил дом, не вырастил сына, не посадил дерево, разве ты настоящий мужчина? Слава Аллаху, у меня хорошая крепкая семья. В октябре 1970 года с Фаридой Ахтямовой из деревни Татар Такаше мы создали её. Жили счастливо, как пара лебедей. Вырастили двоих детей. Сын Айдар, родившийся в 1971 году, отслужил в армии, в Нагорном Карабахе, был награждён медалью. Теперь трудится в пожарной части. Вместе с женой – Алсу растят моих внуков Нияза и Алию. Не могу наглядеться и нарадоваться за них. Дочь Алсу получила медицинское, педагогическое образование, окончила Казанский финансово-экономический институт. Работает в Казани. Они – моя гордость!

В жизни ничего не бывает случайного. И моё происхождение тоже. Род Гимазетдиновых-Гимадиевых крепкий, трудолюбивый, смекалистый. Кого ни возьми из родственников – все достигли больших успехов, оставались всю жизнь верными выбранной профессии, не позволяли

ничем запятнать род. Как этому не радоваться! В сегодняшних достижениях отражается стремление наших предков матерей и отцов, бабушек и дедушек к знаниям и к свету. Наше сегодняшнее поколение не просто продолжает дело отцов-матерей, но возносит его к высшим ступеням почета и уважения. Прошлое и настоящее соединено в наших душах и ведет нас по жизни, направляемое тысячами невидимых нитей. Ещё энергичнее, ещё напористей, ещё проворней нынешние, чем те, кому они обязаны жизнью! Это меня несказанно радует: судьба родины, Татарстана зависит от старания и упорства вот таких джигитов. Я знаю, будущее России в руках вот таких джигитов. Это бесспорно: взять четырёх татар, разбросанных по белу свету – трое живут-поживают и трудятся в России.

Добавлю о себе: мой труд был достойно оценен. Руководители были довольны моей работой, сослуживцы относились ко мне с уважением, а я к ним с любовью. За время работы был награждён почётными званиями «Заслуженный работник транспортного хозяйства Татарстана», «Заслуженный автотранспортник Российской Федерации», «Почётный транспортник России», «Отличник пассажирского

транспорта Республики Татарстан». Первым в Менделеевском районе удостоен звания «Человек – золотое сердце» и, что вызывает особую гордость, мне первому дали звание «Заслуженный гражданин Менделеевского района». Кроме этого в моём архиве хранится множество почётных грамот.

Жизнь прожита не зря: я жизнью, а мир мной остались довольны! Я в это верю. Будьте счастливы, мои родные, земляки, соотечественники!

**Зуфар ГИМАДИЕВ,**
*город Менделеевск.*

## *Мине эшкә өйрәтте*

Мин Зөфәр абыйдан дүрт яшькә кечерәк. Без бергә үстек. Мине эшләргә өйрәтте: печән чабу, утын кисү «серләрен» абыйдан өйрәндем. Башка эшләрдә дә һәрчак аның ярдәмен, киңәшен тоеп тордым.

Арабызда дүрт кенә ел булса да, аңа тормышны башлавы авыргарак туры килде. Әтиебез сугыштан инвалид булып кайтты. Сугышның соңгы көннәрендә Берлинда авыр яралана, госпитальдә ята һәм, шактый соңга калып, көз көне генә өйгә кайтып керә. Бер кулы гомер буе эшкә яраксыз булып калды.

Сугыш еллары хакында күп сөйләнелә. Тылда да җиңел булмый. Дүрт ел эчендә йорт-каралтылар начар хәлгә килә. Заманалар авыр, колхозчылар көч-хәл белән җан асрый. Кием җитешле түгел, ашау такы-токы. Кыскасы, ул дәвер афәтләре безнең гаиләне дә читләп үтмәде. Әле исемдә, әнинең ипи пешергәнен көтеп ала идек. Оны юк бит аның, ишле гаиләгә ике көн саен ипи салырга кирәк. Шикәрне сирәк күрә идек. Бала-чаганың аягына җиткереп булмый.

Яз көннәрендә Зөфәр абый басуга барып, саз ерып, ялан кыр өстендә казынып, үткән көздә алынмый калган черек бәрәңге – кәлҗемә җыеп алып кайта иде. Сыер ташланган вакытларда аеруча кыенга туры килә. Зөфәр абый кул чанасына печән төяп, үзе тартып Бондюг базарына печән сатарга чыгып китә. Безнең якта биек Тихие Гора тавы бар. Печән төялгән авыр чананы шушы тауга ничек тартып менгерә алган ул, уйласам, хәзер дә исем-акылым китә. Шул тау аша үткән юлдан пристаньнан заводка тоз ташыйлар иде. Тоз коелып, юлдагы карны «ашап» бетерә. Чана шумый, абыйның, әле буыннары да ныгып бетмәгән үсмер малайның, җан тирләрен чыгарып, печән чүмәләсен биек таудан тартып менүе күз алдына килә дә, күзгә яшьләр бәреп чыга.

Шоферлык курсларын тәмамлап чыккач та, яше җитмәү сәбәпле машинага утырмыйча, йөк төяүче булып эшләде. Бар эшләп тапканын гаиләгә кайтарып бирә иде. Ул чорда машиналар аз иде, бераз соңрак машина руле артына утырды. Шофёр һөнәрен яратты, бу эшне җиренә җиткереп башкарды. Яшь кенә килеш иске машина белән «чирәм җирләргә», уңыш җыярга да барып кайтты. Әйтүе генә җиңел, сабыйлыгы чыгып җитмәгән бала ниләр күрмәгәндер дә, ниләр ки-

чермәгәндер. Аннан исән-сау кайтуына сөенеш-тек. Көнбатыш Украинада, ракета гаскәрләрендә армия хезмәтен үтте.

Армиядан соң автотехникум тәмамлады. Утыз елдан артык АТП директоры хезмәтен башкарды. Район җитәкчесе итеп кайдан (Актаныштан, Түбән Камадан, Казаннан, Чаллыдан), кемне генә җибәрмәсеннәр, урындагы җитәкчеләрне алыштырып бетерә торганнар иде, тик берсе дә Зөфәр абыйга кагылмадылар, эш кешесен тиз танып ала иделәр, тиздән бу «тану» тирән ихтирамга күчә иде. Гомерен эшкә багышлады дисәм, ялгыш булмады. Хезмәте һәрнәрсәдән өстен иде, җанын-тәнен бирен эшләде. Районда гына түгел, Татарстан буенча ул җитәкләгән АТП 1-2 урыннан төшмәде. Кешеләр белән мөгалләмәсе туры, эш мәсьәләсендә таләпчән иде. Эшендә, кая бакма, тәртип, оешканлык күзгә ташланды. 35 еллап җитәкче булып эшләп, шәхси байлык турында уйламады. Хатыны Фәридә белән агачтан гади, җыйнак кына йорт төзеп керделәр. Әле дә истә, аларга кайтканда, абый белән җәмәгате икәүләп кул пычкысы белән бүрәнә башлары кисеп мәш килүләрен күреп, гаҗәпләнә идем. Кисәләр, аны күтәреп бурага өяләр – шулай итеп бергәләп йорт җиткерделәр. Кеше яллап та эшләтергә

була бит, юк, ул алай итә алмый, кечкенәдән үз эшен үзе эшләргә өйрәнгән иде шул.

Абыем гомер буе кешеләргә ярдәмчел булды, күңеле киң иде. Җыр-моң яратты, шигырьләр язды. Хатыны Фәридә белән бер яңа җыр ишетсәләр, аны тиз генә өйрәнеп, безгә гармунда уйнап, җырлап тыңлаталар иде. Бу сүзләрем, китап – аның рухына дога булып барып ирешсен иде. Урының оҗмахта булсын, абыем!

**Мөнәвир ГЫЙМАЗЕТДИНОВ,**
*Татарстанның атказанган төзүчесе,*
*«Подряд» Җаваплыгы чикләнгән җәмгыять*
*генераль директоры.*

## *Научил меня работе*

Брата Зуфара я младше на четыре года. Мы росли вместе. Именно он научил меня работе: секретам косить сено и рубить дрова. И во многом другом я чувствовал его помощь, мне помогали его советы.

Несмотря на то, что разница в возрасте была небольшой и исчислялась четырьмя годами, его детство было труднее. Отец вернулся с войны инвалидом. Последнее ранение он получил в Берлине в последние дни войны и только осенью, с большим опозданием, вернулся домой. Одна рука всю жизнь была непригодна к работе.

Про годы войны сказано много. В тылу тоже было несладко. За четыре года дом и надворные постройки пришли в упадок. С горем пополам колхозники влачили жалкое существование. Не хватало одежды, еды – с гулькин нос. В общем беды того времени не обошли нашу семью стороной. До сих пор вспоминаю, как мы с нетерпением ждали, когда мама испечёт хлеб. С мукой проблемы, а хлеб большой семье требуется каждый день. Сахар видели очень редко. Обуви

на всех не хватало. Весной Зуфар шёл в поле, утопая в грязи, копался, отыскивая остатки прошлогодней мёрзлой, полугнилой картошки и нёс её домой. С молоком было туго, особенно перед отёлом. Зуфар абый грузил на сани сено и вёз его продавать на сенной базар Бондюги. В нашей стороне есть взгорье, называемое Тихие горы... До сих пор удивляюсь, как он мог подниматься на гору, волоча за собой воз сена. По дороге через эти горы возили с пристани соль. Просыпавшись, она «съедала» снег на дороге. Сани отказывались катиться, и брат, тогда неокрепший подросток, прикладывал невероятные усилия, проливая семь потов, пытаясь сдвинуть воз с места. Представляя эту картину, слёзы наворачиваются на глаза.

Окончив шофёрские курсы, но по возрасту не имевший права сесть за баранку, трудился грузчиком. Всё заработанное приносил и отдавал семье. Он сел за руль только через некоторое время – тогда и самих машин было мало. Профессию свою он любил, и все силы отдавал работе. Будучи совсем ещё молодым на своей старой машине ездил собирать урожай на целине. Это представить трудно, сколько выпало ему, чего он только не повидал, чего не испытал он – маль-

чишка недавно расставшийся с детством. Мы радовались, когда он вернулся живым и здоровым.

Армейскую службу проходил в ракетных войсках на Западной Украине. После армии окончил автотехникум. Более 30 лет трудился директором АТП. Кого только из районного руководства Актаныша, Нижнекамска, Казани, Челнов не поменяли на эти годы, местное начальство сменилось не один раз, но Зуфара никогда не трогали. Работягу узнавали в нём быстро, а затем «узнавание» переходило в глубокое уважение. Без преувеличения: всю жизнь он посвятил работе. Труд для него был превыше всего, работал, вкладывая всю душу. Возглавляемое им АТП не только в районе, но во всём Татарстане долгое время удерживало 1-2 места. К людям относился ровно, в работе требовал самоотдачи. В глаза всегда бросались порядок и организованность. Около 35 лет проходил в начальниках, не думая о собственной выгоде, корысти и обогащении. С женой Фаридой построили обычный деревянный дом. Помню, приехав в гости и увидев, как они вдвоём простой ручной пилой во дворе бревно пилят, удивлялся, глядя на эту ручную работу. А они так вот за бревном бревно сруб поднимали. Ведь можно было нанять ко-

го-нибудь, так нет, не мог он так – с малых лет к самостоятельному труду приученный.

Всю жизнь брат приходил на выручку людям, отзывчивый был, человеком с широкой душой. Любил музыку, песни, писал стихи. Если где услышит новую песню, тут же мелодию на гармошке подберёт, слова выучат с Фаридой, исполнят так, что заслушаешься.

Эти мои слова и эта книга пусть дойдут молитвой до его души.

Пусть твоим местом будет рай, брат мой!

**Мунавир ГИМАЗЕТДИНОВ,**
*Заслуженный строитель Татарстана,*
*генеральный директор ООО «Подряд».*

## *Шигъри җанлы кеше эшлекле җитәкче дә*

Автортранспорт предприятиесенең генераль директоры Миннезөфәр Гыймадиевны районда белмәгән кеше юктыр. Чөнки ул кайдандыр чакырып китергән кеше түгел, үзебезнең районда туып-үскән егет. Бүгенге көндә алтмышын түгәрәкләп килә торган, зирәклек җыйган һәм зур тәҗрибә туплаган җитәкче. Катлаулы, икътисади кыенлыклар чорында базар мөнәсәбәтләренә яраклашып, ныклы адымнар белән алга атлый автотранспорт предприятиесе. Бүгенге көндә акционерлашкан, районда йөк ташу һәм пассажирларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнә.

Генераль директор М.Гыймадиев җитәкчелегендә коллективта 75 кеше эшли. Үзенең үҗәтлеге, сүзеннән кире кайтмавы, әйткәнне җиренә җиткерергә тырышуы белән алдына максат итеп куйганның күбесен чынга ашыруга ирешә Миннезөфәр Хәммәтович. Буш вәгъдәләр биреп, юкка ышандырып йөрергә яратмый. Төгәллеге өчен дә хөрмәт итәләр аны хезмәттәшләре. Бар икән – бирә, юк икән – анысын да өздереп әйтә

белә. Сүзе белән эше бервакытта да аерылмый, диләр аның турында. Кадрлар барысын да хәл итә, дигән гыйбарә белән дә килешә торгандыр җитәкче. Чөнки үз тирәсенә булдыклы, вазифаларын күңел биреп башкара торган белгечләр җыйган. Эксплуатация бүлеге начальнигы Е. Потапова белән алар дистә елдан артык бергә эшлиләр. «Гади, кеше хәлен аңлый торган, әмма шул ук вакытта үзенә карата да, хезмәттәшләренә карата да таләпчән җитәкче ул», – ди Евгения Юрьевна. 12 елдан артык инде аның сәркатибе, кадрлар буенча эшне алып баручы В. Ямщикова да аның турында яхшы фикерләр генә әйтә. Эшләгән кешене күрә һәм тиешле бәясен бирә белүе – җитәкче характерында сыйфатларның берсе. «Тотынгач, эшне ахырына җиткерергә кирәк!» дигән принцип белән яши. Булдыксызлыкны, артта сөйрәлүне өнәп бетерми. Дөрес, мактаганны бар кеше дә ярата. Әмма бит әле мактауга лаек булырлык эш күрсәткечләре дә кирәк.

Предприятиедә уңай үзгәрешләрне хезмәткәрләре аның исеме белән бәйли икән, димәк, бу аның эшчәнлегенә бәя буларак яңгырый. Саный китсәң, андый эшләр автотранспорт предприятиесе исәбендә җитәрлек. Материаль-техник базаны ныгыту, хезмәткәрләрнең эш урынын гына

түгел, яшәешен яхшыртуны алга бурыч итеп куючы кеше ул. Предприятие территориясен яшелләндерү, төзекләндерү буенча быел яз көне генә дә шактый эш башкарылды. Административ бинаның әйләнә-тирәсендә тәртипсез рәвештә үсә торган кыргый өрәңге агачлары чистартылып, алар урынына алмагачлар утыртылды, шунда ук гөлләр үстерер өчен түтәлләр ясалды, көзен алар төрле төстәге чәчәкләргә күмелеп, күңелләрне шатландырып утырырлар. Бина эче генә түгел, гаражлар һәм башка корпуслар да ремонтланды, киңәшмәләр залы җиһазландырылды. Көнкүреш бинасында мунча һәм ял итү бүлмәсе эшли. Хезмәткәрләргә сменаларын тәмамлагач юынып, чистарынып, ял итеп алу өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Менә шуңа күрә дә коллективта югары квалификацияле, тәҗрибәле кадрлар күп һәм алар озак еллар армый-талмый халыкка хезмәт күрсәтәләр. Беренче класслы шоферлар да предприятиедә җитәрлек. Әле күптән түгел генә булып узган техник карау нәтиҗәләре буенча алар сафына тагын берничә кеше өстәлде. Киләчәктә тырыш, намуслы хезмәтләре белән җитәкчелекнең ышанычын аклар алар.

Гади хезмәт кешесенә хөрмәт Гыймадиевлар гаиләсендә кечкенәдән тәрбияләнә. Җиде бала-

лы ишле гаиләдә уртанчы булып, малайчактан ук авыр эштә чыныгып үсә Миннезөфәр. Техниканы белүче, аңлаучы белгеч булуы да аның файдасына. Бу аның кул астында эшләүчеләрне ныклы контрольдә тотарга ярдәм итә. Эш күрсәткән ир елдан-ел югарырак үрләр яулый. Васильево автотранспорт техникумын тәмамлап кайткан яшь егет предприятиенең техник контроль бүлегенә контролер итеп билгеләнә. Ул вакытларда АТП да кадрлар бүлеге начальнигы булып эшләгән Билалетдин абый Вәлиев (хәзер инде чал чәчле пенсионер) әйтүенчә, Миннезөфәр Хәммәтович тырыш, гадел һәм үзенә ышанып тапшырган вазифаны намус белән, зур җаваплылык тоеп башкара торган кеше. Механик, баш инженер һәм башка белгечлекләрне үз башыннан үткәреп, менә инде 10 елдан артык ул – предприятиенең алыштыргысыз җитәкчесе.

М.Гыймадиев фикеренчә, кеше сәләтенчә эшләсен, тәртип ягы аксамасын. Эленке-салынкы йөрүчеләрне, хезмәт дисциплинасы бозучыларны яратмый. Кирәк икән андыйларга катгый җәзасын да үз вакытында бирә белә. Шуның өчен югарыдагы җитәкчеләр дә аның эшчәнлеген югары бәяли. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының «атказанган транс-

портчысы», «Россиянең почетлы автотранспортчыс», «Пассажирлар йөртү хезмәте отличнигы» – болар генераль директор лаек булган мактаулы исемнәрнең бер өлеше генә. Моннан тыш республика һәм район тарафыннан бирелгән күпсанлы Мактау кәгазьләре үзләре генә дә күп нәрсә турында сөйли. Шуның өстенә шигъри җанлы кеше дә ул Миннезөфәр Хәмәтович. Шигырь язу белән ул күптәннән мавыга. Аның иҗат җимешләре безнең район газетасында сирәк булса да басылып чыга. Күренекле композиторлар аның шигырьләренә көй язып, җыр итеп радиодан да кайчак яңгыраталар. Ул гына түгел, халкыбыз җырларын, авыл көйләрен гармунда сузарга да һәвәс ул Зөфәр ага. Бик арыган вакытларда, күңеленә урын таба алмаганда, кулына яшьлек дустын – тальян гармунын ала һәм аның телләренә басып уйнаганда, яңадан туган кебек сафланып китә.

Агымдагы ел Гыймадиевлар өчен тагын бер ягыннан истәлекле. Аларның шатлыгын арттырып, бәхет өстенә бәхет өстәп, тәүге оныклары Нияз туды. Бабасы өчен бу икеләтә сөенечле хәбәр, чөнки нәселне дәвам итүче булды. Миннезөфәр Хәммәтович шушы көннәрдә үзенең юбилеен билгеләп үтә. Юбилярны котларга аның

дуслары, хезмәттәшләре, туганнары, балалары җыйналыр. Билгеле инде, бу бәйрәм табынының хуҗабикәсе Миннезөфәр аганың тормыш иптәше Фәридә дә бик якты күңелле ханым. Аларның бер-берсенә терәк булып, шатлык-борчуларны бергәләп кичереп, ничә дистә еллар үткәргәннәр, ул һәм кыз үстергәннәр. Аларның икесе дә бүгенге көндә гаилә горурлыгы. Тормышта үз урыннарын тапканнар. Горурлана алырлык балалар үстерә юбилей көненә зур бүләк түгелмени?

**М.САФИНА.**

*«Менделеев яңалыклары» газетасы. 2002 ел.*

# *Кредо – жить по чести*

В Менделеевске есть добрая традиция в дни юбилеев чествовать заслуженных людей, да так, чтобы было слышно в округе. – с этих слов начал приветственную речь руководитель района Игорь Привалов в адрес замечательного человека – Миннезуфара Хамматовича Гимадиева на торжественном вечере в честь его 70-летия.

Миннезуфар Гимадиев – коренной бондюжец с яркой трудовой биографией, отмеченной многочисленными наградами. Радость торжества, состоявшегося в ресторане «Золотая подкова», он разделил вместе с многочисленными гостями – бывшими коллегами, руководителями предприятий, родными и близкими, друзьями. С поздравительной миссией прибыл на светлый душевный праздник советник депутата Госсовета РТ Р. Ханбиков, бывший глава района Рустам Гафаров, при поддержке которого Менделеевское автотранспортное предприятие под руководством Миннезуфара Хамматовича успешно проходило испытание временем, пережив период кризиса в экономике страны и на

предприятии. За долголетний подвижнический труд герою нашей зарисовки присвоены звания «Почетный транспортник РФ», «Заслуженный работник транспорта Республики Татарстан», «Почетный автотранспортник России», «Отличник пассажирского транспорта РТ». Признание его заслуг отмечено самой высокой в районе наградой – он одним из первых стал почетным гражданином Менделеевского района. Множество почетных грамот республиканского и районного руководства, ОАО «Корпорация «Татавтотранс» хранится в его семейном архиве. Недавно юбиляру решением Союза транспортников России вручена медаль «100 лет со дня рождения Е. Т. Трубицына» – первого министра транспорта РФ, Героя социалистического труда. Горячо и искренне поздравляя именинника,бывшие коллеги-транспортники из Казани, Нижнекамска, Набережных Челнов, Альметьевска, Арского, Мамадышского, Нурлатского, Сабинского, Азнакаевского районов, отметили его лучшие человеческие качества, позволившие на протяжении долгих лет работы оставаться образцом руководителя, безгранично преданного профессии.

К своему любимому делу он шел год за го-

дом, вначале постигая азы специальности в Мамадышской автошколе, затем в Васильевском автотранспортом техникуме, Казанском комбинате повышения классности. После трехлетней службы в армии в ракетных войсках Западной Украины оттачивал профессиональное мастерство в УТТ «Прикамнефть» Елабуги.

В Менделеевском АТП начал работать с 1969 года начальником отдела технического контроля, через год главным инженером, затем начальником Менделеевской автоколонны Елабужского АТП. В 1990 году менделеевские автотранспортники отделились от Елабуги, М. Гимадиев был назначен директором вновь образованного коллектива. Вверенное ему предприятие стало флагманом автотранспортного хозяйства республики. Вручая юбиляру памятный адрес, генеральный директор ОАО «Корпорация «Татавтотранс» Динар Миннуллин отметил весомый вклад М. Гимадиева в развитие транспортной отрасли района.

Уникальные деловые качества Зуфара были заложены в раннем детстве. Он появился в свет 18 июня четвертым ребенком в семье самых уважаемых тружеников села Бизяки. Достойны светлой памяти мама Гульсум и отец Хамат, вос-

питавшие шестерых детей, давшие всем образование. Непререкаемый авторитет родителей служил ярким примером для подражания, скрепляя надежными узами большую семью Гимадиевых. Они дружны и по сей день. Вместе собираются в праздничные дни, поддерживают друг друга в трудные минуты.

Адресуя добрые слова юбиляру, младший брат Мунавир, генеральный директор ЗАО «Трест «Подряд» в г. Набережные Челны, почетный гражданин города, заслуженный строитель РТ, и единственная сестра Мансура, работавшая долгие годы председателем сельпо, Бизякинского сельсовета, отметили, что Зуфар был самым покладистым и трудолюбивым, не боялся никакой работы и, видимо, поэтому было предначертано судьбой впоследствии помогать матери ухаживать за больным отцом, старшим – закончить обучение в вузах. Равиль окончил военное училище, служил в пограничных войсках. После успешного завершения Московской военно-политической академии им. Ленина занимал высокие военные посты в чине полковника. Ныне живет в Москве. Мансур после окончания КСХИ работал главным агрономом, председателем колхоза «Власть Советов». Рашит – специалист

«Татгазэнерго», Анвар (ныне покойный) был капитаном речного плавания, заслужил орден Трудового Красного Знамени.

– Среди бизякинцев семья Гимадиевых пользуется заслуженным уважением. Они истинные патриоты малой родины. Всегда придут на помощь тем, кто в этом нуждается, – сказал Ибрагим Галимов, директор ООО «Колхоз «Кама».

– Это бескорыстный человек, открытый, честный и порядочный. Я не услышал от него в свой адрес ни слова критики. Он всегда старается только помочь добрым советом, – подтверждает его преемник генеральный директор ОАО «Менделеевское АТП» Рамиль Муратов.

На протяжении вечера мы поняли, что жизненное вдохновение черпает наш юбиляр в окружении дорогих сердцу людей. Вниманием и заботой окружает обаятельная жена Фарида, радует успехами на трудовом поприще сын Айдар, специалист МЧС и дочь Алсу, заместитель генерального директора по экономическим вопросам ПАТП-1 г. Казани. Его обожают внуки. А еще о Миннезуфаре Гимадиеве можно сказать, что он творческий человек: пишет лирические стихи о красоте родного края. Некоторые из них

положены на музыку местных татарских композиторов. Подарком к юбилею стали песни, в том числе и авторские, в исполнении Ильдара Фаразутдинова, Раушана Гатауллина, Гульнары Шаймардановой, танцевальные композиции народного ансамбля эстрадного танца «Кристалл». Пусть и в дальнейшем Аллах оберегает династию Гимадиевых от бед и невзгод, дарует побольше радостных и светлых мгновений. С юбилеем, уважаемый Миннезуфар Хамматович.

**Л.КРИВИЛЕВА,**
*«Менделеевские новости», 2002 г.*





І бүлек

# *Мине монда туган туфрак тарта*

**Мин бәхетле! – Туган халкым белән**
**Горурланып яшим дөньяда.**
**Авырлыклар безне һич куркытмый,**
**Сез, дусларым, янда булганда.**



I глава

# *Меня сюда зовёт земля родная*

Я счастлив! – Довелось на свете жить
С моим народом и гордиться им.
И не пугают трудности ничуть,
Друзья, когда плечом к плечу стоим.

# *Татарстан – туган ягым*

Татарстан – минем туган ягым,
Синдә үтте яшьлек елларым.
Чит җирләрдә бәхет эзләмәдем,
Синдә үттем гомер юлларын.

Авылымның изге чишмәләре
Саф суларын бүләк иттеләр.
Якташларым минем, дус-ишләрем
Һәр вакытта якын иттеләр.

Мин бәхетле! – Туган халкым белән,
Горурланып яшим дөньяда.
Авырлыклар безне һич куркытмый,
Сез, дусларым, янда булганда.

Тату яши бездә бар халык та.
Татар иле якын барысына.
Ыгы-зыгы килгән җирләр булса –
Менә бездән үрнәк алсыннар!

Җитәкчебез безнең Тимер кеше,
Җиңел түгел, беләм, зур эше!
Татарстан яклап кояш чыкты,
Җанны сыйпап җылы җил исте.

Татарстан – минем туган ягым,
Нур тирбәлә дулкын өстендә.
Дуслык белән, тыныч тормыш белән
Без горур да, батыр, көчле дә!



# *Татарстан – мой край родной*

Мой Татарстан – родная сторона,
Здесь юности моей прошли года.
Я счастья не искал в чужих краях,
Здесь путь проложен раз и навсегда.

Водою деревенских родников
Святой и чистой с детства я храним.
Родным считался я средь земляков,
Среди друзей-товарищей – своим.

Я счастлив! – Довелось на свете жить
С моим народом и гордиться им.
И не пугают трудности ничуть,
Друзья, когда плечом к плечу стоим.

Народы здесь живущие – дружны.
Татарский край соединил пути.
И если кто охочий до войны,
Пример пусть с нас берёт – куда идти.

Большое дело и нелёгкий труд –
Храня покой, руководить страной.
У Татарстана – настоящий путь,
У Татарстана – солнце за спиной.

Мой Татарстан – мой благодатный край,
Луч света по-над жизненной волной.
Спокойно в мире-дружбе пребывай
И будем мы горды, сильны с тобой!



# *Их, дускаем!*

Их, дускаем, җырлыйк әле,
Былбыллардан калышмыйк.
Бар сагышлар читкә китсен,
Кайгыларга сабышмыйк.

Их, дускаем, уйныйк әле,
Тальян гармуннар тартып.
Күңелләрне ачыйк әле
Туган авылга кайтып.

Эчик әле чишмә суын
Көмеш савыт тутырып.
Бераз яллар итик әле,
Тау буенда утырып.

Күл өстендә пар аккошлар
Канатларын кагына.
Сагышларым алып кайтты
Мине туган ягыма.

# Эй, друг мой!

Эй, друг мой, давай запоём,
Подобием став соловью.
Печаль пусть обходит наш дом,
Грустить-горевать ни к чему.

Эй, друг мой, сыграем давай,
Тальянки меха развернём.
Вернувшись в отеческий край,
С души пыль дорог отряхнём.

Попьём родниковой воды,
Наполнив хрустальный сосуд.
Присядем, окончив труды,
У горки, где ивы растут.

Встревожив озерную гладь,
Два лебедя мимо плывут...
Печаль иль тоска, как узнать,
На родину больше зовут.

# *Кайтам әле туган авылга*

Кайтыйм әле туган якларыма,
Эчим әле чишмә суларын.
Сызгырып ла тагын үтәр идем
Бәбкә куган инеш буйларын.

Инеш буендагы тал-тирәкләр,
Кая сезнең сылу чагыгыз?..
Кая безнең матур Пирәнәдә
Балык тотып йөргән чагыбыз?..

Туган якның матур болыннан
Җырлый-җырлый үтәр идем мин.
Яңа чапкан печән өсләрендә
Ятып яллар итәр идем мин...

Булмас инде, булмас беркайчан да,
Хыялларым үксеп яндылар.
Болыннарым, чабар печәннәрем
Су астында инде калдылар.

Ә шулай да кайтам, кайтам әле тагын,
Туган якка, туган авылга.
Мине монда туган туфрак тарта,
Мәңгелеккә шунда калырга.

# *Я вернусь в родную деревню*

В края родные я вернусь усталый,
Воды из родника коснусь устами.
Насвистывая, вновь пройдусь вдоль речки,
Где хворостинкой гнал гусят беспечно.

Сплетает ветви над рекой ракита,
Не в ней ли время молодости скрыто?
Не в нашей ли прекраснейшей Пиране
Пора рыбалки предрассветной ранью?

В родном краю красивыми лугами,
Ходил бы и ходил, стихи слагая.
На скошенной траве, на копнах свежих
Лежал бы и лежал в мечтах-надеждах.

Уже не будет, никогда не будет.
Мечты сгорели в пепелище судеб.
Луг заливной, покосные угодья
Остались навсегда под половодьем.

Но я вернусь, мне так необходимо
В родимую деревню, в край родимый.
Меня зовёт земля моя родная,
Чтоб с ней и в ней остался навсегда я.

# *Бәзәкә болыннары*

*(Түбән Кама ГЭСы төзелү уңаеннан)*

Киләм дә тау итәгенә,
Күз саламын еракка.
Бер карыймын акчарлакка,
Бер карыймын аръякка.

Уйлар китә үткәннәргә.
Яшь тула күзләремә:
Болыннарым су астында,
Яшьлегем эзләре дә...

Су өсте тулы акчарлак,
Кайда яшел аланнар?..
Кайда күлләр, кайда урман,
Кайда кызыл баланнар?..

Таңнарда кошлар сайрамый,
Алар кая киттеләр?
Киттеләр алар кайтмаска,
Безне ятим иттеләр.

Болыннарны су бастырып,
Түрәләр нишләдегез?
Табигатьне тар-мар итеп,
Зур зыян эшләдәгез.

Аннан-моннан гына уйлап,
Башкарасыз зур эшләр.
Сүз бит эштән аерыла,
Ил кадәр илкәй нишләр?..

Катгый әйтәм – җитте сезгә!
Бәлки җитәр көчегез –
Күктә болыт кумагыз сез,
Җиргә, җиргә төшегез!



# *Бизякинские луга*

*(в связи со строительством Нижнекамской ГЭС)*

Прихожу к обрыву часто,
Там, куда ни кинешь глаз:
В синем небе только чайки,
Да вода кругом сейчас.

И уводит мысль в былое,
Подступают слёзы вдруг:
Юность скрылась под водою,
Под водой цветущий луг.

Над водою только чайки.
Где леса, озёра где?
Где поляны иван-чая?
Где калина? Всё в воде...

Птиц не слышно щебетанья –
Все исчезли без следа.
Не оставив на прощанье
Ни надежды, ни гнезда.

Под водой поля оставить –
Что чиновник, ты творишь?
Чем такой урон исправишь?
Как природу воскресишь?

Как попало покумекав,
Не дела творят – разбой.
Если мыслят мелкой меркой,
Что-то станет со страной?..

Заявляю всем: Довольно!
Хватит пусть ума и сил,
Не гонять мечты над полем,
А на землю опустить!



# *Тугайларымны сагынам*

Тау буендагы болынга
Йөрдек без җиләкләргә.
Хәзер анда чал дулкыннар...
Зар-сагыш йөрәкләрдә.

Сагынып кайтам да авылга,
Яшьлек юлларын үтәм.
Болын тулы гөл-чәчкәләр, –
Дулкын астына киткән.

Акчарлаклар, әйтегезче,
Яшьлек эзләрем кайда?
Дусай, Пинәрә күлләре,
Кайда сез, кайда, кайда?..

Кабатланмас гүзәллекләр
Сыкрыйдыр су астында.
Кем һәм кйчан ил алдында
Җавап тотар барысына?

# *Скучая по заливным лугам*

Возле гор в широкие луга
Мы детьми по ягоды ходили.
Ныне все под волнами седыми...
Грусть-тоска бьёт в сердца берега.

По деревне заскучав, вернусь,
Чтоб пройтись по молодости тропам,
Мысленно цветы лугов потрогать –
Под водой, но помню наизусть.

Чайки, подскажите мне, прошу,
Молодости след не на воде ли?..
Озеро Дусай, Пинаре где вы?
Где места, к которым так спешу?

Красоты неповторимой след
Мучится и стонет под водой.
Кто перед народом и страной
Будет, наконец, держать ответ?



# *Без татарлар...*

Татарстан – туган ягым,
Казан аның башкаласы.
Хакын яклап, хөрлек саклап
Күпме кеше баш салган соң?..

Чит илләрдә бәхет эзләп,
Күпме вакыт җәфа чиккән?..
Шахталарда күмер чукып,
Себерләрдә урман кискән...

Кимсетүләр эзсез үтми –
Зәгыйфьләнгән туган теле.
Ничә гасыр көрәшкән ул
Динен саклап, саклап денен.

Без татарлар, булыйк горур,
Горурларга баш орырлар.
Күңел китек чакларда да
Татар үлмәс җырын җырлар.

Без татарлар, тырыш халык,
Сука тартып җирен сөргән.
Иман саклап күтәрелгән,
Куркытмаган аны сөрген.

Җон оекбаш, чабатасын
Аягыннан төшермәгән.
Гадәтләрен, йолаларын
Чит-ятларга күчермәгән.

Без татарлар – яугир халык,
Сугышларда баш бирмәдек.
Башны кискән чакларда да
Тез чүкмәдек, бирелмәдек!

Татарстан – туган ягым,
Казан – гүзәл башкалам.
Бабамнарның дәүләт тоткан
Чакларына ашкынам!



*Гыймадиевлар Зөфәр*
*һәм Фәридә оныклары*
*белән. 2007 ел.*

# *Мы татары...*

Мой Татарстан – мой край родимый, славный
Казань была и есть твоей столицей.
За независимость, за соблюденье права
Платили люди судьбами сторицей.

А сколько настрадалось на чужбине
За счастьем устремившись – не сочтёте?
Лес вековой рубили по Сибири,
Рубили уголь в копоти и поте...

Калечат человека униженья,
Родной язык калечится тем паче.
Века прошёл он, избежал забвенья,
Его никто не смог переиначить.

Татары мы – идём по жизни гордо,
И гордой головы склонять не станем.
И пусть душа обожжена народа,
В бессмертных песнях род татарский славим.

Татары мы – веками со стараньем
Пахали землю и тянули лямку.
Мы пережили веры развенчанье,
Не дали никому её заляпать.

Посконные штаны, носки да лапти
К ногам за годы прикипели прочно.
Но чужеродной не найдём заплатки
В обрядах и обычаях мы точно.

Татары мы – своих достойны предков.
Не кланялись снарядам при сраженьях,
И пусть сносило голову нередко,
К победам шли, сквозь горечь пораженья.

Мой Татарстан – мой край родимый, славный
Казань была и есть твоей столицей.
Край предков был могучий и державный –
Есть чем гордиться и к чему стремиться.



*Төп йорт янында.
Сулдан: Мөнәвир,
Зөфәр, Мансура, Рәшит,
Мансур. 2006 ел.*

# *Уйлану*

Су буенда, чирәмлектә,
Ялгыз уйлап утырам.
Үтә гомер, картаябыз,
Илле бишне тутырам.

Күз алдына китерәмен,
Балачагым елларын.
Еракка даны таралган
Бәзәкә болыннарын.

Ничек инде онытасың,
Печән чапкан чакларны?!.
Сызылып таң аткан чакта
Кешнәп чапкан атларны?!.

Бата-чума сазлыгында
Аз чапмадык күрәнен.
Сазлык диеп тә тормадык,
Шунда куйдык кибәнен.

Әлсерәп тамак кипкәч, без
Суны эчтек сазлыктан.
Күрше күлдә коенмадык –
Вакытыбыз азлыктан.

Хәзер инде башка вакыт, –
Печән үсә кырларда.
Чалгы белән дә чапмыйлар.
Ишетелми җырлар да.

Үзгәртеп корабыз диеп,
Болгаттылар заманны.
Үзгәрделәр кешеләр дә,
Белми дусны, туганны.

Җитте вакыт уйланырга,
Кеше гомере бик кыска.
Иман белән яшик, дуслар,
Үтмәсен гомер бушка.



# *Размышление*

На лугу сижу возле речки.
В одиночестве думать легче.
Сколько зим и вёсен идти
От пятидесяти пяти?..

Годы детства себе представлю.
Я охранникам к ним приставлен.
Нас Бизякинские луга
Прославляли по округам.

Как забудешь покоса время?!
На заре, вскинув ногу в стремя,
Помню, гнали табун коней,
Подгоняя их все сильней.

По колено в болотной топи
Сколько скошено было осоки.
Да, болото и что с того –
Шапкой стог водрузим на него.

Если жажда одолевала,
Из болота воды пивал я.
А купаться в озере – блажь,
Если в деле поймал кураж.

Времена другие настали,
И травой поля зарастают.
Кто сегодня косит косой,
Кто поёт, кто ходит босой?

Перестройка у нас по слухам,
Нашептали народу в ухо,
И разладилась жизнь людей:
Знать не знают родню, друзей.

Наступило раздумий время и
Век короткий людского племени.
Так давайте жить верно, друзья,
Чтобы жизнь проходила не зря.



* * *

Ялгыз калган аналарның
Хәлләре бик аяныч.
Аналарга балалары
Булсын иде таяныч!



* * *

Положение печально
Одиноких матерей.
Мать детей растит, чтоб стали
В старости опорой ей.





II бүлек

# Йолдыз тезгән безнең юлыбыз

Ак чәчкәләргә карыйм да,
Күңел нечкәреп китә.
Сабыр итәм, көннәр үтә,
Яшь гомерем сине көтә.



II глава

# Звездами устланы наши дороги

Если белые снова я вижу цветы,
Сердце млеет от их неземной красоты.
Дни проходят: смиренно сношу и в терпенье
Жду, когда в мою молодость спустишься ты.

# *Ак чәчкәләр*

Май аенда алмагачлар
Күзнең явын алалар.
Сандугачларның сайравы
Сагышларга салалар.

Әй, дускаем, гүзәл кошым.
Каян килә сиңа моң?
Сайрар идем синең кебек,
Моңым җитми, нишлим соң?..

Ак чәчкәләргә карыйм да,
Күңел нечкәреп китә.
Сабыр итәм, көннәр үтә,
Яшь гомерем сине көтә.

# *Белые цветы*

В мае месяце яблони буйно цветут,
Их цветы ослепляют, они там и тут.
Соловьи распевают. Вот только их пенье
Своим свистом весёлым вгоняет в тоску.

О, подруга, прекрасная птица моя,
Отчего твои песни печали таят?
Я подобно тебе рассыпался бы в трелях,
Есть слова, но не знаю мелодии я?

Если белые снова я вижу цветы,
Сердце млеет от их неземной красоты.
Дни проходят: смиренно сношу и в терпенье
Жду, когда в мою молодость спустишься ты.

# *Исеңдәме?..*

Салкын кышлар үтте,
Ямьле язлар җитте,
Гөрләвекләр шаулап актылар.
Ап-ак булды бакча,
Таңнар шундый якты,
Алмагачлар чәчәк аттылар.

Яз көннәре матур,
Илгә кошлар кайтты,
Тал-тирәктә кошлар сайрыйлар.
Кызлар бездә матур,
Егетләре батыр,
Айлы кичтә йолдыз саныйлар.

Фәридәкәй, дустым,
Биек күккә аштык,
Йолдыз тезгән безнең юлыбыз.
Иң яктысын алып,
Учларыңа салып,
Гомер буйлап атлап барырбыз.

# *Помнишь ли ты?..*

Зима прошла, и вот –
Весна-красна идёт
И говорок разносится ручьёв.
Стал сад – сплошь белый цвет
И светлым стал рассвет.
Светло от яблонь и от соловьёв.

Прекрасны дни весны.
Вновь с дальней стороны
Вернулись птицы – слышишь,
свищет дрозд.
А девушки цветут,
И парни их зовут,
Чтоб под луной заняться счётом звёзд.

Друг милый, Фарида,
Давай пойдём туда,
Где звёздами усыпаны пути.
Я лучшую из звёзд
Тебе в ладонь принёс,
Чтоб свет её помог нам жизнь пройти.

* * *

Кинәт кенә болыт кубарыла
Якты йолдызларны каплый ул.
Тик мәхәббәт сүнми,
Йөрәк ярын күзли,
Сөю хисен мәңге саклый ул.

* * *

Сгустятся внезапные тучи
И звёзды закроют на миг.
Любовь и тогда не погаснет,
Влюблено посмотрит и ясно,
И чувств глубину сохранит.

*Зөфәр, Фәридә үзләре йорты янында.*



# Фәридәм

Борчу килсә, елмаюың белән
Сагышымны син ул тараткан.
Ачык йөзле, кешелекле җан син,
Ходай сине шулай яраткан.

Таянычым булып яшә һәрчак шулай,
Син бит минем бәхет кояшы.
Тормыш юлын бергә үтәбез без,
Ышанычлы гомер юлдашым!

# Моя Фарида

Улыбнешься, когда я тревожусь,
И рассеются горести вмиг.
Создана ты Всевышним такою:
С чистым ликом целебный родник.

Будь опорой мне в жизни и солнцем,
Солнцем счастья моим на года.
Ты – надёжная спутница жизни
Ты – мой путь под названьем Судьба.



*Зөфәр, Фәридә үзләре йорты янында.*

# *Тапсыз сөю*

Бакчаларда кошлар сайрый,
Җырлыйсы килә минем.
Яшьлегемне ялгышлардан
Саклыйсым килә минем.

Гармунымны алдым кулга,
«Түгәрәк күл» уйнадым.
Уйнадым да, җырладым да,
Сине генә уйладым.

Сандугачлар сайравында
Өмет бар ул, сынадым.
Бергә булган вакытларны
Мин минутлап санадым.

Мин генәме мәхәббәттә
Үз ярын югалтмаган?..
Йолдыздай якты сөюне
Мин беркайчан тапламам.

Ялгышлар да, сагышлар да,
Җанны әрнетеп тора.
Күңелемдә җыр яралды,
Бары яхшыга юра!

*1969.*

## *Чистая любовь*

Сад щебетаньем полнится
И хочется мне спеть.
Ведь от ошибок молодость
Сберечь, как не хотеть.

Гармошку взял я на руки,
Запел и заиграл.
Хоть пел о Круглом озере,
Тебя лишь вспоминал.

Надеждами наполнены
И песни соловья.
Когда мы были счастливы,
Считал минуты я.

Как будто только я один
Возлюбленных терял?..
Звезду свою бессмертную
И небосвод ронял.

Грустится, ошибается
И душу гложет боль.
А песня, что рождается,
Предскажет пусть любовь.

*1969.*

* * *

Син ашыкма, дустым, адашты, дип,
Миңа ярдәм кулы сузарга.
Мәхәббәткә үзем тап төшердем,
Үзем тиеш аны юарга.



* * *

Что заблудился, друг мой, не тверди,
И не клянись пожертвовать собой.
Смог запятнать – сумею обелить
Сам неповинную ни в чём любовь.





# *Сагыну хисләре*

Сагыну хисендә янам,
Оныта алмыйм, дускаем.
Серләремне уртаклаша
Ярда үскән кушкаен.

Кушкаенга мин сөйкәлдем,
Хәлем беткәнгә күрә.
Сагынуны баса алмыйм,
Өзелеп сөйгәнгә күрә.

Идел буйлары бик ямьле,
Йөзеп китәсем килә.
Сөйгән ярым, синең белән
Гомер итәсем килә.

*1968. Васильево.*

# *Тоска*

В огне тоски своей горю,
Забыть, мой друг, тебя не в силах.
С берёзой тайной поделюсь,
Что надвое ствол разделила.

К стволам спиною прислонюсь.
Они мне силы не удвоят.
Тоску свою не разделю,
Как не разнять любовь с душою.

А Волга плещет широко
И переплыть бы, да опасно.
С тобой, возлюбленной моей,
Прожить бы жизнь, коль ты согласна.

*1968. Васильево.*

# *Оныта алмыйм*

Оныта алмыйм, дустым, Фәридәкәй,
Онытырга тиеш булсам да.
Синең алда мин зур гаепле, дип,
Башларымны иеп торсам да.

Оныта алмыйм, дустым, Фәридәкәй,
Күңелләрем керсез булса да.
Сине сагынам, ныграк сагынам мин,
Ел артыннан еллар узса да.

Менә тагын язлар килеп җитте,
Гөрләвекләр шаулап агарлар.
Җылы яктан кошлар кайтыр илгә,
Сандугачлар чут-чут сайрарлар.

Туктап тыңла, дустым, Фәридәкәй,
Сандугачның асыл җырларын.
Сандугачка кушылып син дә җырла,
Таралсыннар сагыш-моңнарың.

Сагышларга бирелә күрмә, дустым,
Сагыш бит ул җанны саргайта.
Мин бирелдем авыр сагышларга,
Сагыш мине яшьли картайта.

Кулларыма гармунымны алам,
Их, сыздырып бер көй уйнарга!
Күңелләрем тулсын,
Җанга рәхәт булсын,
Тиеш түгел егет еларга!

Гармун тавышы моңлы бигрәк,
Көйне сайларга кирәк.
Йөрәкләрне дөрләп яндырырлык
Ярны сайларга кирәк!

Аерылган ярлар була алар,
Кавышулар була кабаттан.
Мин ышанам, очрашырбыз әле,
Мин һаман да сине яратам!

Үлгәндә дә әйтеп үләр идем,
Сөйгән ярым – син ул иркәм, дип.
Йөрәгемдә иң-иң түрләрендә
Синең исемеңне йөртәм, дип.

Тормышымда төрле хәлләр булды,
Адаштым мин кайчак юлларда.
Ахыр чиктә кайтып баш куярмын
Кайтып синең җылы кулларга!

## *Не могу забыть*

Не могу забыть, подруга Фарида,
Хоть по-правде должен был давно забыть.
Пред тобою я виновен был тогда.
Хоть казнись, хоть не казнись – не свяжешь нить.

Не могу забыть, подруга Фарида,
Хоть душа моя чиста перед тобой.
Все сильней скучаю я, грущу всегда,
Хоть года мои проходят чередой.

И вот-вот весна наступит, и вот-вот
Зажурчат ручьи, капели зазвенят.
Птицы к нам уже отправились в полёт,
Мы вот-вот услышим трели соловья.

Встань, послушай, дорогая Фарида,
Благородное звучанье соловья.
Пусть от грусти не останется следа,
Пусть рассеется тоска-печаль твоя.

Пусть тоска не будет властна над тобой,
Не заставит беспрестанно горевать.
Потому я стал до времени седой,
Что с тоской решился век свой вековать.

Ремешок гармошки вскину на плечо.
Эх, сыграть бы мне искусно хоть разок!
Пусть подступит к горлу ком – оно не в счёт,
Пусть мелодия мне душу пропечёт –
Не допустит, чтоб джигит от слёз промок!

У гармони мелодичен голосок,
Если выбрана мелодия под стать.
И сердца заполыхают в унисон,
Если правильно любимых выбирать!

Всё случается: расстанутся порой,
А потом опять сойдутся, чтобы жить.
Верил, ждал, что снова встретимся с тобой,
Ни на миг не прекращал тебя любить!

В свой последний час признался бы тебе,
Ты одна моей возлюбленной была.
В самом сердце, в заповедной глубине
Имя я твое берёг, не забывал.

В жизни всякое бывает, знаю сам,
Можно сбиться по пути и заплутать.
Вот вернусь к твоим врачующим рукам,
Чтобы голову сложить и сердце сдать!



* * *

Ак кәгазьгә язып куям әле,
Онытмагыз, алып укыгыз:
Дус дигәнең сатып куя икән,
Дошман була икән якының...

* * *

Изреченье запишу на чистый лист,
Не забудь, возьми, прочти и поделись:
Другу веришь – он продаст почём зря,
Враг же может оказаться в друзьях...



# *Кызыма*

*(яраткан кызым Алсуга)*

Туган көнең белән котлыйм, кызым,
Ак бәхетләр теләп калам мин.
Сиңа дигән изге теләкләрне
Күңел җырларыма салам мин.

Теләкләрем кабул булсын, кызым,
Аллаһыдан ныклап сорыйм мин.
Бар тормышың матур, якты булсын,
Гел яхшылык кына юрыйм мин.

Мин ышанам, кабул булыр, кызым,
Син бәхетем, безгә таяныч.
Картлык килсә килер, безнең өчен
Син бит, балам, бетмәс куаныч!

# Дочери

*(любимой дочке Алсу)*

Дочка, поздравляю с днём рожденья
Дней безоблачных желаю, море счастья.
Для тебя сложил я песню-посвященье,
Чтоб душевность слов и чувств
смогли вмещаться.

Моя доченька, пусть сбудутся желанья,
Пусть услышится Аллахом, что просил я.
Пожелания мои, как заклинанье:
Жизнь твоя пусть будет светлой и красивой.

Верю, доченька, всё будет непременно.
Счастье ты моё, опора нам под старость.
И стареть не страшно, если видим смену.
Ты, дитя, мне нескончаемая радость!

# *Ял йортында*

*(шаяру)*

Су буендагы талларым,
Җилсез дә шаулашалар.
Ял йортында ялгызлар юк,
Бик тә тиз парлашалар.

Читләп кенә карап торам,
Шундый матур пар болар.
Бүген бергә, иртәгәсен –
Араларда яр булыр.

Барысы да парлы-парлы,
Ничек туры килгәннәр?
Киемнәрнең матурларын,
Иң яхшысын кигәннәр.

Сагышланып йөрим менә,
Беръялгызым килгәнгә.
Мин үземне тиңләп торам
Ялгыз үскән имәнгә.

Ялгыз имән корый, диләр,
Каеннар табасымы?..



*Мөнәвир (сулда)*
*һәм Зөфәр.*
*Кисловодск,*
*«Долина роз», 2013 ел.*

Ялгыз башны дулкыннарга
Илтеп бер саласымы?..

Уйланып мин йөрим шулай,
Белмим инде нишләргә?
Парлыларны уйлап ятам,
Хатын керә төшләргә.

Аллаһ бирсә, өйгә кайтып,
Хатынны алып киләм.
Үз-үземне жәлләп йөрмәм,
Ялгыз имән мин, димәм!

# *В доме отдыха*

*(шутка)*

В доме отдыха на фоне природы
Наблюдаю я за нашим народом:
Люди здесь поодиночке не ходят,
Очень быстро себе пару находят.

Я за парами стою-наблюдаю,
Наблюдения на ус свой мотаю:
Нынче вместе, завтра может случиться
Им на разных берегах очутиться.

Внешне пары друг на друга похожи,
Выбирать видать пришлось по одёже.
Разоделись, как на первом свиданьи,
Сразу видно – проявили старанье.

От того, что я приехал без пары
Вот хожу теперь один грустно-старый.
С одиноким дубом сравнивать впору,
Что разросся и стоит под забором.

Я слыхал, что этот дуб погибает...
Что ж берёзонек ему не хватает?..

Хороводят вкруг него в белых платьях,
А ему охота к волнам в объятья.

Так я думаю, хожу-размышляю:
Что мне делать одному здесь – не знаю.
В голове влюблённых парочек лица,
Спать ложусь – во сне жена моя снится.

Даст Аллах, домой вернусь и тогда я
Сяду рядышком с женой, выпью чаю.
И жалеть себя напрасно не буду,
И не буду себя сравнивать с дубом!

*Ялда.*
*Египет.*



III бүлек

# *Бу дөньяда без кунак кына*

**Күңелемне сагыш баскан чакта**
**Гармунымны алам кулыма.**
**Авыл көен уйнап, дәртле җырлап**
**Кайтып киләм яшьлек елыма.**



III глава

# *Мы в гостях в этом мифе*

**Когда тоска одолевает,**
**Беру гармонь. Её лады**
**Мотив старинный звонкий знают**
**Тех лет, где был я молодым.**





# *Баллы чишмә*

Очраштырды безне язмыш,
Баллы чишмә буенда.
Су эчәргә килгән идең
Җәйге сабан туенда.

*Куш.* Эх, дускаем, кил әле,
Баллы чишмә буена.
Таллар да сине сагына,
Син генә бит уемда.

Урамнардан җырлап үттек,
Авыл йоклап яткан да.
Саубуллаштым синең белән
Сызлып таңнар атканда.

*Куш.* Эх, дускаем, кил әле.
Баллы чишмә буена.
Таллар да сине сагына,
Син генә бит уемда.

Сагынып кайттым авылыма,
Төштем чишмә буена.
Таллар белән сөйләшәмен,
Ә син һаман уемда.

*Куш.* Эх, дускаем, кил әле.
Баллы чишмә буена.
Таллар да сине сагына,
Син генә бит уемда.

Көмеш сулар җырлап ага
Тал тамырлары аша.
Сагышларымны җиткерәм
Сиңа җырларым аша.

*Куш.* Эх, дускаем, кил әле.
Баллы чишмә буена.
Таллар да сине сагына,
Син генә бит уемда.

# *Медовый ручей*

Нас свела судьба с тобой
У ручья медового.
С сабантуя за водой
Ты пришла бедовая.

*Припев:* Эх, подруга, приходи
Вновь к медовому ручью.
Ивы сохнут без воды
Я о тебе лишь думаю.

По деревне сонной шли,
Напевая песни мы.
В свете утреней зари
Попрощались весело.

*Припев:* Эх, подруга, приходи
Вновь к медовому ручью.
Ивы сохнут без воды
Я о тебе лишь думаю.

Вновь приехал в край родной
И к ручью спустился я.
Ивы шепчутся со мной,
Что-то разгрустился я.

*Припев:* Эх, подруга, приходи
Вновь к медовому ручью.
Ивы сохнут без воды
Я о тебе лишь думаю.

Серебристая вода
Льётся словно песенка.
Я пою, но и тогда
Без тебя не весело.

*Припев:* Эх, подруга, приходи
Вновь к медовому ручью.
Ивы сохнут без воды
Я о тебе лишь думаю.



# *Изге теләк*

Яңа ел барчабызга да
Зур бәхетләр китерсен.
Карлар яусын, язлар килсен,
Ташулары гөр килсен.

Җылы якка киткән кошлар
Кайтсыннар туган якка.
Алар белә – иң зур бәхет
Яшәве туган якта!

Кояш чыксын, нурын сипсен,
Җиргә җылылык иңсен.
Алмагачлар чәчәк атсын,
Назлы җилләре иссен.

Сандугачлар сайрасыннар,
Кояш нурларын түксен.
Яшел чирәмнәр өсләрендә
Балалар уйнап үссен.

Бирсен Ходай сәламәтлек,
Авырмасын бер кеше.
Изге уйда булсын бәндә,
Җиңел барсын һәр эше.

«Кризис» дигән нәрсәләр
Иске елларда калсын.
Игелек кыла алганнар
Үр яулап алга барсын.

Бай яшәсен бар кеше дә,
Илдә тынычлык булсын.
Ялгызлар парын тапсыннар,
Кырларда иген уңсын.

Илдә туйлар гөрләп торсын,
Матур балалар тусын.
Хуш киләсең Яңа елкай,
Теләкләр кабул булсын!
Амин, ул шулай булсын!

# *Добрые пожелания*

Пусть приходит к нам Новый год.
Пусть приносит он счастье нам.
Снег растает пусть, лёд сойдёт,
Пусть опять зашумит весна.

Пусть вернутся из тёплых стран
Птицы снова к местам родным.
К нам летят они неспроста:
Счастье – жить на родине им.

Пусть восход излучает свет,
Пусть прольёт на Землю тепло,
Чтобы яблонь раскрылся цвет,
Чтобы нежные ветры несло.

Пусть соловушки запоют,
Над травой загудят шмели.
Пусть, играя, дети растут
В каждом доме большой Земли.

Пусть здоровье Аллах нам даст,
Не болеет никто пускай.
Каждый день пусть и каждый час
Доброта льется через край.

Чтобы кризисы, войны, мор
В прошлом канули навсегда.
Можешь делать добро? Будь добр!
И отступит навек беда!

Пусть богатыми станут все,
Пусть в стране воцарится мир.
Урожай пусть даёт посев,
А влюблённость – свадебный пир.

От красивой любви дитя
Пусть красивым, счастливым растёт.
Что ж! Пожалуйте в Новый год!
Даст Аллах, всё произойдёт,
Все что я пожелал не шутя!

## *Хатын-кызларга*

Котлап сезне, хатын-кызлар,
Ак бәхетләр теләп каламын.
Сезгә булган изге хисләремне
Почталарга илтеп саламын.

Язгы кояш гел елмая,
Мартның шушы көнендә!
Йолдызлар яктырак янсыннар,
Сезнең бәйрәм төнендә.

Юлыгызга гөлләр сипсәм,
Салкын тияр гөлләргә.
Күңелләрне җил какмасын,
Тыныч булсын илләр дә.

Сорыйм бары бер Алладан:
Бирсен сезгә сабырлык.
Тормышыгыз матур булсын,
Сагынып искә алырлык.

# *Женщинам*

Женщины, вас поздравляя,
Счастья желаю безбрежного.
Почтой вам всем посылаю
Добрые чувства и нежные.

Солнышко вам улыбается
И по-весеннему светится!
Звёздам пусть ярче сияется
В мартовском праздничном месяце.

Пусть же морозы последние
Ярких букетов не трогают.
Ветры согреют пусть летние,
Мир пусть хранит вас дорогою.

Пусть вам Аллах даст терпение,
Жизнь дарит благополучие.
Маленькое дополнение:
Пусть вспоминается лучшее!



* * *

Быел безнең үгез елы,
Бирсен Ходай илгә муллык.
Үгез кебек армый эшлик,
Булсын безнең холыклар нык!

* * *

Год быка, он стоит на пороге сейчас,
Изобилие родине будет, бог даст.
Так давайте, как бык неустанно трудиться,
Крепким, твёрдым характер пусть будет у нас!



# *Өметеңне өзмә*

Өметеңне өзмә, дустым,
Бирелмә сагышларга.
Эчеңдәге хәсрәтләрне
Сиздермә танышларга.

Сөендермә дошманнарны:
«Бетте бу!» – димәсеннәр.
«Гомер аты аксаклый», – дип,
Сөенеп йөрмәсеннәр.

Җәлләмә үткән гомерне,
Ялгышлары булганга.
Үкенмә, дустым, үкенмә,
Бу дөньяга туганга.

Бәхетне юлга сипмиләр,
Кибеттә дә сатмыйлар.
Бәхетне эзләп табалар,
Аны көтеп ятмыйлар.

Өметеңне өзмә, дустым,
Шатлык сиңа киләчәк.
Көтеп алган бәхет кошың:
«Сиңа килдем!» – диячәк!

## *Не теряй надежду*

Не теряй, мой друг, надежду,
Не впадай в тоску-печаль.
Если вдруг на сердце снежно,
Ты тоски не замечай.

Ты врагов своих не радуй,
Скажут тут же: «Он пропал!»
Захромаешь – скажут: «Падай!»
Злость врагов – она слепа.

Не жалеть былые годы
И ошибок не считать.
Ты на свет явился, чтобы
В небе соколом летать.

Счастьем путь не посыпают,
Не торгуют у ворот,
На диване не мечтают...
Тот, кто ищет – тот найдёт!

Не теряй, мой друг, надежду,
Радость жди, придёт она.
Птицей счастья безмятежно
Раз – и сядет у окна!

# *Яшим әле*

Бу дөньяда без кунак кына,
Вакыт җиткәч китеп барырбыз.
Табиблар да, түрәләр дә китә,
Кемнәр китми? Әйтеп карагыз!

Гомерем буе тырышып эшләп,
Җитмешемне инде тутырдым.
Үткәннәргә нәтиҗәләр ясап,
Озак вакыт уйлап утырдым.

Тормыш – сынау. Төрле яктан
Сынады ул, аяп тормады.
Авырлыкны, авыруын бирде,
Тик аяктан ега алмады.

Сагышларны басар өчен,
Иртә таңнан китәм эшемә.
Башланмаган эшләр байтак икән,
Кирәк икән әле яшәргә!

Хыялларым эшкә ашкындыра,
Ат елында мин бит туганмын.
Яшим әле, ут уйнатып яшим,
Сөендереп дуслар, туганны.
Көендереп кара дошманны.

Күңелемне сагыш баскан чакта,
Гармунымны алам кулыма.
Авыл көен уйнап, дәртле җырлап
Кайтып киләм яшьлек елыма.

Йә Ходаем, үтенепләр сорыйм,
Озынырак итче гомерне.
Бик яшисе килә армый-талмый,
Гөлгә күмеп туган җиремне!



*Сулдан уңга (өстә): Бәшәров Мингали, Гыймадиев Мансур, Гыймадиев Мөнәвир, Гыймадиев Зөфәр; алда: Бәшәрова Рабига, Гыймадиев Әнвәр, Гыймадиева Мәүлидә.*

## *Ещё буду жить!*

Мы в этом мире только гости,
Наступят сроки, все уйдут:
Начальник, врач – все на погосте
Найдут последний свой приют.

Не покладая рук трудился,
Пошёл восьмой десяток лет.
Сейчас назад оборотился,
Чтоб вывод сделать: жил иль нет.

Жизнь – испытанье. Без пощады
Меня крутила так и сяк.
Болезни, трудности, преграды...
Но с ног не сбила – всё пустяк!

Чуть свет, я ухожу в работу,
Чтоб мысль о грустном усмирить.
Дел непочатых много что-то,
А значит нужно дальше жить!

К работе вдохновлён мечтами,
Рождён в год лошади – пашу.
Живу ещё, и жить спешу:
Друзьям на радость отвечаю,
Врагов коварных сна лишу.

Когда тоска одолевает,
Беру гармонь. Её лады
Мотив старинный звонкий знают
Тех лет, где был я молодым.

О Всемогущий, призываю,
Дай подлиннее жизни срок,
Чтобы, цветами засыпая
Родную землю, жить я мог!



*Бертуганнар. Мөнәвиргә 60 яшь. Сулдан Зөфәр, Рәшит, Равил, Мансура, Мөнәвир, Мансур. Белоус, 2006 ел.*

# *Имәннәр шаулый*

Мин гашыйкмын имәннәргә,
Имәннәр шаулавына.
Яшел хәтфә болыннарда
Кошларның сайравына.

*Куш.* Тау буенда яшь имәннәр
Нигә сез шауламыйсыз?
Өзгәләнә йөрәккәем,
Сез шуны аңламыйсыз.

Кулымдагы гармунымны
Элеп куйдым имәнгә.
Йөрәгемдә ялкын дөрли,
Сине сагынып сөйгәнгә.

*Куш.* Тау буенда яшь имәннәр
Нигә сез шауламыйсыз?
Өзгәләнә йөрәккәем,
Сез шуны аңламыйсыз.

Кавышмадык иркәм белән,
Китәм инде, имәннәр...
Аерылып куя икән
«Мәңге бергә!» – дигәннәр...

*Куш.* Тау буенда яшь имәннәр
Нигә сез шауламыйсыз?
Өзгәләнә йөрәккәем,
Сез шуны аңламыйсыз.



# *Шумят дубравы*

Я влюблён в дубы,
В шум седых дубрав,
В голос певчих птиц,
В шёлк травы в лугах.

*Припев:* Молодые дубы на пригорке
Отчего не шумите листвой?
Сердце в горе заходится горьком,
А для вас это звук пустой.

Я свою гармонь
Дубу предлагал.
Мне огонь любви
Сердце выжигал.

*Припев:* Молодые дубы на пригорке
Отчего не шумите листвой?
Сердце в горе заходится горьком,
А для вас это звук пустой.

Вместе быть навек
У дубов клялись,
А теперь пути
Наши разошлись.

*Припев:* Молодые дубы на пригорке
Отчего не шумите листвой?
Сердце в горе заходится горьком,
А для вас это звук пустой.



# *Ялгыз каен*

Яр читендә, су буенда,
Үсә ялгыз бер каен.
Шул каенны сагынып кайтам,
Син искә төшкән саен.

Ялгыз каен, син дускаем,
Ямансулама инде.
«Оныттылар мине», – диеп,
Начар уйлама инде.

Төшләремә керәсең дә,
Телгәлисең үзәкне.
Меңгә, йөзгә телгәлисең,
Яраланган йөрәкне.

Язлар җиткәч, чирәм үскәч,
Без кайтырбыз тагын да.
Ходай исәнлекне бирсен,
Бирсен эшен, ялын да.

Яр читендә, су өстендә,
Йөзә парлы аккошлар.
Берәүгә дә җиңел түгел,
Катлаулы ул язмышлар.

Онытырга мөмкинме соң –
Син безнең изге каен.
Йөрәккәйләр мең өзелә
Син искә төшкән саен.

Яр читендә ялгыз каен,
Сокландырмый кемнәрне?
Минутлап санап барамын,
Сиңа кайтыр көннәрне.



*Фәридәгә 60 яшь. Сулдан: Зөфәр абый, кызы Алсу, хатыны Фәридә, улы Айдар, оныклары. Ижевка, 1 февраль 2007 ел.*

# *Одинокая берёза*

На прибрежье у самого края
Одиноко береза растёт.
К ней, соскучившись, я приезжаю,
К ней, тебя вспоминая, влечёт.

Ты, берёза, одна мне подруга,
Но тоску нагонять не спеши,
Мол, забыли меня. Эта мука
Светлой памятью в сердце лежит.

Мне любимая снится ночами
И мне до крови душу саднит
Сто, нет тысячу раз, замечал я
От любви моё сердце болит.

Дай, Аллах мне здоровья покрепче,
Дай работу и отдых мне дай.
По весне мы вернёмся к той речке
И увидимся вновь невзначай.

Наблюдая, как лебеди парой
Проплывают по глади речной,
Понимаю, что судьбы задаром
Не даются в юдоли земной.

Разве можно забыть мне берёзу,
Что святилищем стала навек?
Сердце тысячу раз душат слёзы,
Только вспомню наш первый рассвет.

На прибрежье, у самого края
Есть берёза – влюблённых приют.
Дням отсчет я веду и считаю,
Что дороги нас вместе сведут.

*Туганнар Сабан туенда.*
*2007 ел.*







# Эчтәлек

*I бүлек*

## Мине монда туган туфрак тарта


Татарстан – туган ягым ........ 58
Их, дускаем! ........ 62
Кайтам әле туган авылыма ........ 64
Бәзәкә болыннары ........ 66
Тугайларымны сагынам ........ 70
Без татарлар... ........ 72
Уйлану ........ 76
«Ялгыз калган аналарның...» ........ 80


*II бүлек*

## Йолдыз тезгән безнең юлыбыз


Ак чәчкәләр ........ 84
Исеңдәме?.. ........ 86
«Кинәт кенә болыт кубарыла...» ........ 88
Фәридәм ........ 90
Тапсыз сөю ........ 92

Син ашыкма, дустым, адашты, дип...» ........... 94
Сагыну хисләре ........................................ 96
Оныта алмыйм ........................................... 98
«Ак кәгазьгә язып куям әле...» ..................... 102
Кызыма ................................................... 104
Ял йортында ............................................ 106

*III бүлек*

**Бу дөньяда без кунак кына**

Баллы чишмә ..........................................112
Изге теләк .............................................116
Хатын-кызларга ...................................... 120
«Быел бездә үгез елы...» ........................... 123
Өметеңне өзмә ........................................ 124
Яшим әле ............................................... 126
Имәннәр шаулый ..................................... 130
Ялгыз каен ............................................ 134

# *Содержание*

*I глава*

**Меня сюда зовёт земля родная**

Татарстан – мой край родной ........................... 60
Эй, друг мой! ................................................ 63
Я вернусь в родную деревню ........................ 65
Бизякинские луга ........................................... 68
Скучая по заливным лугам ........................... 71
Мы татары... ..................................................74
Размышление ............................................... 78
«Положение печально...» ............................. 81

*II глава*

**Звездами устланы наши дороги**

Белые цветы ................................................. 85
Помнишь ли ты?.. ......................................... 87
«Сгустятся внезапные тучи...» ..................... 89
Моя Фарида .................................................. 90
Чистая любовь .............................................. 93

«Что заблудился, друг мой, не тверди...» ....... 95
Чувство тоски ................................................ 97
Не могу забыть ............................................. 100
«Изреченье запишу на чистый лист...» ........ 103
Дочери ............................................................ 105
В доме отдыха ............................................... 108

*III глава*

**Мы в гостях в этом мире**

Медовый ручей ...............................................114
Добрые пожелания .........................................118
Женщинам ...................................................... 121
«Год быка, он стоит на пороге сейчас...» ...... 124
Не теряй надежду .......................................... 125
Ещё буду жить! ............................................... 128
Шумят дубравы .............................................. 132
Одинокая берёза ............................................ 136

*Литературно-художественное издание*

Гимадиев Зуфар
(Гимадиев Зуфар Хамматович)

*ПОМНИШЬ ЛИ ТЫ?..*

Подстрочный перевод: *Альфия Ситдикова*
Художественный перевод: *Вера Хамидуллина*

Казань. 2018.
На татарском и русском языках

*Әдәби-нәфис басма*

Гыймадиев Зөфәр
(Гыймадиев Зөфәр Хәммәтович)

*ИСЕҢДӘМЕ?..*

Әдәби мөхәррире *Ф. М. Сафин*
Бизәлеш мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы
*И. З. Фәррахов*

16+ Знак информационной продукции согласно
ФЗ от 29.12.2010 г. № 436-ФЗ

Оригинал макеттан басарга кул куелды 9.07.2018.
Форматы 60х90 $^{1}/_{32}$. Басма табагы 4,5.
Тиражы 100 д. Заказ Т-258.